ДИҢГЕЗ КҮРЕНМИ

Бәясенә кызыгып ялга барырга җыенган кешеләр акчасыз да, сәфәрсез дә калды

> 5

ТЫРЫШКАН ТАБАР

Авыл халкы үзе җитештергәннән табыш алу ягын кайгырта

> 6

РАБИТ БАТУЛЛА:

«Әштә ата белән угыл мөнәсәбәте булмый»

> 18

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 138 (29105) | Җомга | 22 сентябрь | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

«Татар-информ»

КӨТӘ БЕЛҮЧЕЛӘР

БЕР ЕЛ ЭЛЕК ИЛДӘ ӨЛЕШЧӘ МОБИЛИЗАЦИЯ ИГЪЛАН ИТЕЛДЕ

Меңләгән гаиләгә кагылды бу вакыйга. Күпләр улларын, ирләрен, әтиләрен махсус хәрби операциягә озатты. Алар бу сынауны ничек кичерә, нинди өмет белән яшиләр, бу ел аларны нәрсәгә өйрәтте? «Хәзер бар да башкача. Иртәбез алар турында уйлап башлана, ятканда да уебызда – алар. Бездә бары бер теләк: исән генә була күрсеннәр! Көрешергә насыйп булсын!» – диләр газизләрен озатып калучылар. Якыннарыннан яхшы хәбәр көтеп көн күрүче кешеләрнең хәлен белештек.

> 17

Ишетми калмагыз

Россиядә автомобиль бензинын һәм дизель ягулыгын чит илләргә сатуга вакытлыча чикләү кертелде. Хөкүмәтнең телеграм-каналында хәбәр ителгәнчә, бу карар эчке базарда ягулык бәясен тотрыклыландыру максатыннан кабул ителгән. Чикләүләрнең, ягулык базарын тулыландырып, бәяләрне киметүгә ярдәм итүе көтелә. Моңа кадәр Министрлар Кабинеты биржага бензин һәм дизель ягулыгын җибәрү нормативларын арттырган иде. Шулай ук авыл хуҗалыгы җитештерүчеләре өчен ягулык сатып алуга көндәлек мониторинг оештырылган.

Ил Хөкүмәте вице-премьеры Татьяна Голикова әйтүенчә, 2030 елга илдә хезмәткәрләргә ихтыяҗ артачак. Хезмәт базарында шундыйрак вазгыять фаразлана. Илдә 15–19 яшьлек кешеләр саны арта, ә 30–39 яшьлекләр, киресенчә, кими. Голикова фикеренчә, махсус урта һәм югары белемле белгечләр әзерләү, шулай ук мәктәп укучыларына һөнәр сайларга булышу мәсьәләләрен башкачарак хәл итәргә туры киләчәк. Мәгариф һәм кадрлар әзерләү программалары хезмәт базарындагы үзгәрешләргә карап эшләнәчәк.

Мошенниклар Татарстанда яшәүче ике пенсионерның 2 миллион сумга якын акчасын урлаган. Эчке эшләр министрлыгы матбугат хезмәте хәбәренә караганда, Түбән Кама районында бер аферист, 70 яшьлек ир-атка телефон аша шалтыратып, янәсе, банк счетыннан акчасын алырга маташуларын белдергән. Байлыгыннан коры калмас өчен, кодларын әйтүне сораган. Шуннан соң пенсионерның счетыннан 1,1 млн сумнан артыграк акчасы юкка чыккан. Мошенниклар шундый ук ысул белән Алабугада яшәүче 68 яшьлек хатын-кызны 800 мең сум акчасыннан мәхрүм иткән. Әлеге очраклар буенча җинаять эшен кузгату турында мәсьәлә карала.

Алдагы көннәрдә Татарстанда җылы һәм коры һава көтелә. Республикада хөкем сөргән циклон нәтиҗәсендә әбиләр чуагы дәвам итә.
Гидрометеоүзәк мәгълүматларына караганда, шимбә һәм якшәмбе – 23, 24 сентябрьдә һава температурасы нормадан 7–9 градуска югарырак булачак. Явым-төшем ихтималы зур түгел.
Ял көннәрендә көндезге һава температурасы, рекордлы күрсәткечләргә якынлашып, +21…+27 градуска җитәчәк. Төнге сәгатьләргә килгәндә, шимбә – 23 сентябрьдә +7…+14, якшәмбе – 24 сентябрьдә +5…+10 градус булачак.
Синоптикларның башлангыч фаразлары буенча, дүшәмбе – 25 сентябрьдә яңгыр яварга мөмкин. Көндез һава температурасы +21…+26 градус чикләрендә тирбәләчәк. Сишәмбе – 26 сентябрьдә урыны белән аз гына яңгырлар көтелә. Һава температурасы берникадәр төшеп, көндез +19…+24 градус тәшкил итәчәк.

БӘЙСЕЗ БУЛАСЫ КИЛӘ

ТАТАРСТАН БАШКАЛАСЫНДА ЦИФРЛАШТЫРУ ТУРЫНДА СӨЙЛӘШТЕЛӘР

Kazan Digital Week – 2023

Алтын, нефть, газ гына түгел, хәзер мәгълүмат һәм технологияләр дә аерым кыйммәткә ия булган заманда яшибез. Юкка гына аны «икътисадның каны» дип атамыйлар. Канның үзебездә «агуы» кирәк. «Kazan Digital Week – 2023» халыкара форумында да моңа аеруча басым ясадылар.

Санлы дөнья

Татарстан башкаласы дүртенче тапкыр «Kazan Digital Week – 2023» халыкара форумын кабул итә. Бу юлы – федераль статуста. Катнашучылар күбрәк, хәл итәсе мәсьәләләр җитдирәк, димәк. Форумның пленар утырышында да тукталдылар аларга.

Дөнья буенча санлы технологияләр юнәлешендә көндәшлек бара. Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов үз чыгышында шуңа игътибар итте.

– Ил Президенты да технологик бәйсезлеккә ирешү максатын куйды. Бу, иң элек, илкүләм куркынычсызлык мәсьәләсе дә. Татарстанда әлеге максатка ирешү өчен барысы да эшләнә, – диде Рәис.

Беренче чиратта, бу – инфраструктура. Татарстанның бу җәһәттән күзгә күренерлек эшләре бар. Казанда быелтыр ачылган яңа IT паркны гына алыйк. Анда 600ләп компания эшли, араларында мәгълүмати технологияләр юнәлешендә лидер саналганнары да бар.

– IT инфраструктура республиканың зур шәһәрләрендә генә түгел, районнарда да бар. Хәзер сигез районда IT мәйданчыклар эшли. Мондый мәйданчыклар һәр муниципалитетта булырга тиеш, – дип тә искәртте Рөстәм Миңнеханов.

Төзеден дә бетте түгел, үзебезнең «акыллы баш»лар да кирәк. Рәис әйтүенчә, республика вузлары хәзер дүрт меңләп IT белгеч әзерләп чыгара. Әмма тармак өчен бу гына аз. «10 меңгә җиткерергә кирәк», – дигән бурыч куйды республика Рәисе. Моның өчен югары уку йортларына бу юнәлеш буенча абитуриентларны кабул итүне киңәйтергә, белем бирү сыйфатының дәрәҗәсен сакларга, ә предприятиеләргә мондый кадрлар белән кызыксынырга кирәк.

Цифрлаштыру бурычлары кәгазьдә генә калмыйча, һәр кешенең тормышына үтеп керергә тиеш. Мондый бурычны дәүләт башлыгы да куйган иде. Ерактагы якын технологик бәйсезлекне якынайту өчен эш барамы соң инде? Россиянең цифрлы үсеш министры Максут Шадаев сүзләре белән әйтсәк, Россиядә 820 мең программист бар. Бу бер ел элек булган саннан 15 процентка күбрәк. Илнең «акыллы баш»лары уйлап тапкан IT продукциягә дә ихтыяҗ 10 мәртәбә арткан. Дәүләт тә ярдәменнән ташламый, ди министр. Шулай булгач, киләчәккә якты өмет белән карыйсы.

Дөрес, технологик бәйсезлек турында сөйләр өчен, иң башта үзебездәге «тимер», ягъни электроника кирәк. Россиянең сәнәгать һәм сәүдә министры урынбасары Василий Шпак шул фикердә.

– XX гасырда икътисадның каны булып нефть, углеводород торса, XXI гасырның каны булып мәгълүмат тора, – диде урынбасар. – Бу кан башкаларда агарга тиеш түгел. Бер яктан караганда, Татарстанның фәнни һәм сәнәгый мөмкинлекләре, моңа өстәп, кунакчыл һәм дус булуы җитәрлек.

Күргәзмәдә күргәннәр

Форумның күргәзмәсендә «үзебезнеке» дип мактанырлык яңалыклар тәкъдим ителгән иде. Барысы да бар: компьютерлар өчен программа тәэминаты да, сине бер сүздән аңлый торган ясалма интеллект та, «Москвич» белән «Атом» да. Күргәзмә белән форум кунаклары, җитәкчелек тә танышты.

«Москвич» димәктән. Күргәзмәдә күпләрнең игътибарын җәлеп иткән экспонат, мөгаен, шул булгандыр. Гадәти машина түгел ул. ЮХИДИ хезмәте өчен махсуслаштырылган. «Кибер-шериф» дигән махсус системага корылган. Автомобиль юлда йөрүчеләрнең нинди кагыйдәләрне бозуын тикшереп торачак: тизлек арттыру, парковка мәсьәләсе дисеңме. Йөзне дә яшереп булмас: машина аны да үзенә терки һәм базага кертә. Әлегә ЮХИДИ карамагында бу бердәнбер машина. Күз-кышны чыксын әле, аннан карарбыз, диләр.

«Атом» исә бөтенләй гаҗәпләндермәкче. Күргәзмәдә әлеге электромобильне тәкъдим иткән Хәким Хөсәенов аңлатканча, «Атом»ның алгы тәрәзәсе 3D эффект белән җиһазландырылып, юлда йөрүне тагын да уңайлырак итәчәк. «Фильмнардагы «бэтмобиль», «Железный человек»ның дисплее кебек инде ягъни. Навигаторда кая юл тотуыңны билгелисең дә, машина тәрәзәсендә барысы да күрсәтелеп барылачак», – дип аңлатты ул «ВТ»га. Электромобиль 500 км кадәр юлны уза ала, ди.

Әмма машинаның ничә сум торасын сер итеп саклыйлар. Мәгълүм булганча, аны җитештерү 2025 елда «Москвич» заводында башланачак. Компаниянең үзеге исә Чаллыда калачак.

Казан дәүләт мәдәният институтында киемне... ясалма интеллект тегә икән! Дөресрәге, институт базасындагы Инженерия үзәгендә кием-салым дизайнын ясалма акыл белән берлектә уйлап тапканнар. Нәрсә булганын үз күзләребез белән күрдек – форумның пленар утырышында халыкка мода күрсәттеләр. Матур, әлбәттә!

Тагын бер гаҗәпләндергән проект – «Газпром-СПКА»ның космик спутнигы. Дөрес, әлегә макеты. Бу проект җирне космостан күзәтергә, төгәлрәк әйткәндә, «парник эффекты»н контрольдә тотарга мөмкинлек бирәчәк.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

Форум – саннарда

- 31 илдән 20 мең катнашучы
- 1,3 мең спикер
- Форум бюджеты – 35 млн сум
- Күргәзмәдә 216 компания катнашты
- 10 юнәлеш буенча 138 стенд урнаштырылды

«Kazan Digital Forum – 2023» халыкара форумы кысасында төрле тармакларга бәйле фикер алышулар уза. Берсендә пилотсыз эшләүче транспорт һәм аны камилләштерү турында сөйләштеләр.

Республиканың Фәннәр академиясе президенты Рифкать Миңнеханов белдергәнчә, хәзерге вакытта Татарстанда предприятиеләрнең ихтыяҗлары өчен М1 классы 50дән артык пилотсыз электрон платформалар җитештерелгән. Аларның санын 100гә җиткерергә җыеналар. Нигездә әлеге җайланмалар «склад – җитештерү урыны – склад» маршруты буенча йөри.

Иннополиста да пилотсыз транспортны сынау бара: анда шундый 10–11 такси йөри. Күптән түгел «КАМАЗ»ның да роботлаштырылган йөк машинасы юлга кузгалды. Шоферсыз гына.

2021 елда «Алабуга» махсус икътисадый зонасында «беспилотник»ларны сынау өчен мәйданчык әзерли башлаганнар иде. 2023 елда анда тәүге сынаулар узачак. Кадрлар мәсьәләсе дә кузгатылды. Кешесез йөрсә дә, контрольдә тоту өчен барыбер «акыллы башлар» кирәк бит. Пилотсыз транспорт чаралары белән идарә итү өчен белгечләрне Казан авиация институтында, Иннополис университетында һәм Казан дәүләт энергетика университетында әзерлиләр.

ТАТАРСТАН ТӘҖРИБӘСЕ

Алдынгы тәҗрибәне күрергә. Россия Хөкүмәте башлыгы урынбасары Виктория Абрамченко Казанга эш сәфәренең максатын әнә шул сүзләр белән аңлатты. Ул, республика җитәкчелеге белән берлектә, биологик чистарту корылмаларын, Казанның чүп яндыру заводы төзелеш мәйданчыгын карады, Самосырово полигонында башкарылган эшләр белән танышты.

Биологик чистарту корылмаларын ул Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов белән барып күрде. Биредә төзекләндерү эшләре «Экология» илкүләм проектының «Иделне торгызу» федераль проекты һәм төбәктәге махсус программа кысасында бара. Реконструкциядән соң бу корылмалар зур күләмдә юынтык суны кабул итә һәм чистарта алачак. Бу – шәһәр төзелеше өчен дә гаять мөһим эш.

– Мин Казанга алдынгы тәҗрибәне күрергә дип килдем һәм чынлап та канәгать калдым, – диде Виктория Абрамченко. – Илдәге барлык чистарту корылмалары шактый тузган хәлдә. Шәһәрләр совет чорында төзелгән чистарту корылмаларыннан тора. Аларны үзгәртергә кул җитми иде. Казанда чистарту корылмалары Идел буендагы иминлеккә дә бәйле. Без Рөстәм Миңнеханов белән сөйләштек. Бу алдынгы тәҗрибәне ил күләмендә кулланырга кирәк. Моның өчен семинарлар оештырып, фикерләшергә кирәк булыр.

Моннан тыш ул башкаладагы калдыкларны утильләштерү заводы (ЗЭУ) төзелеше белән дә танышты. «Мин Казан халкына шунысын әйтә алам: таләпләргә туры килмәгән завод төзелешенә юл куймаячакбыз», – диде ул.

Самосырово полигонындагы эш барышы белән дә таныштты федераль вице-премьер. Бирегә 2019 елдан бирле чүп ташымыйлар. «Безнең бурыч – 2024 ел азагына кадәр шәһәрләрдә урнашкан иң куркыныч 191 чүплекне юк итү», – дип искәртте ул.

Казанга Россия оборона министрының беренче урынбасары Руслан Цаликов та килде. Ул Россия Президентының Идел буе федераль округындагы тулы вәкаләтле вәкиле Игорь Комаров һәм Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов белән башкаладагы «Батыр» үзәген барып карады. Министрлар Кабинетында алар катнашында киңәшмә узды.

УРТАК ТЕЛ

Дагыстан башкаласы Махачкалада «Россиянең тарихи-мәдәни мирасы» IX парламент форумы ачылды. Аның эшендә Дәүләт Советы Рәисе, Россия Федерация Советы каршындагы Милләтара мөнәсәбәтләр һәм дини берләшмәләр белән берлектә эшләү советы рәисе урынбасары, Татарстан Халыклары ассамблеясы советы рәисе Фәрит Мөхәммәтшин катнашты.

Россия халыкларының тарихи-мәдәни мирасын саклау мәсьәләләрен игътибар үзәгенә алган әлеге чара, Федерация Советы тәкъдиме белән, 2009 елдан бирле үткәрелеп килә. Быел форум танылган сәясәт һәм җәмәгать эшлеклесе, Дагыстанның халык шагыйре Рәсүл Гамзатовның тууына 100 ел тулуга багышланган. Темасы: «Мәдәни мирас – Россия халыкларының милләтара аңлашу нигезе».

Форум мәйданчыкларында тематик секцияләр утырышлары узды. Фәрит Мөхәммәтшин «Милләтләр, мәдәниятләр, конфессияләр арасындагы хезмәттәшлек һәм дәүләтләрнең, халыкларның дуслыгы» секциясе эшендә катнашты. Парламент башлыгы күпмилләтле Россиядә тынычлык, татулыкны ныгыту өчен мондый форумнарны үткәрүнең мөһимлеген басым ясап әйтте. «Рәсүл Гамзатов, күпмилләтле ватаныбызда халыклар дуслыгының ачык гәүдәләнеше буларак, үзеннән бик бай мирас калдырды, – дип билгеләп үтте Фәрит Мөхәммәтшин. – Безнең республикада Рәсүл Гамзатовның шигырьләре татар теленә 1960 нчы елларда ук тәрҗемә ителә башлады, ә аның «Высокие звезды» әсәре Мәскәүдә рус телендә басылып чыкканнан соң бер ел узуга татар телендә дөнья күрде. Рәсүл Гамзатовның хезмәтләре яшьләрне тәрбияләү эшендә гадәттән тыш мөһим».

Фәрит Мөхәммәтшин фикеренчә, бүген күпмилләтле Россиядә халыклар һәм мәдәниятләр арасындагы элемтәләрне үстерүдә гражданлык җәмгыяте институтлары мөһим роль уйный. «Республикабызда яшәүчеләр телләр, традицияләр, гореф-гадәтләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү белән чиктән тыш кызыксына, – дип билгеләп үтте парламент башлыгы. – Әлеге күпкырлы эшне без Татарстан халыклар ассамблеясы эшчәнлеге аша алып барабыз. Ул инде 30 ел дәвамында республикада яшәүче халыкларның этномәдәни күптөрлелеген саклау, милләтара һәм конфессияара татулыкны саклау өлкәсендәге эшне алып бара. Республикада милләтара тынычлык һәм татулыкны саклау буенча нәтиҗәле эшләүче оешма бу. Аның абруе елдан-ел үсә».

tatarstan.ru

Фәрит Мөхәммәтшин Махачкалада Дагыстан Халык җыены рәисе Заур Әскәндеров белән очрашты. Алар ике республиканың күпьяклы хезмәттәшлеген алга таба үстерү, шул исәптән парламентара элемтәләрне киңәйтү мәсьәләләре буенча фикер алыштылар.

Фәрит Мөхәммәтшин әйтүенчә, һәрбер халык, кайда гына яшәмәсен, һәрвакыт үзенең туган телен, мәдәниятен һәм иң яхшы традицияләрен сакларга омтыла.

«Чит илләргә сәфәрләр барышында республика җитәкчелегенең милләттәшләребез һәм милли-мәдәни автономияләр вәкилләре белән очрашулары безнең республика өчен традициягә әйләнде. Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов һәрвакыт мондый аралашуга игътибар бирә. «Халык дипломатиясе» Татарстанның БДБдәге партнерлары белән сәүдә-икътисадый, мәдәни-гуманитар элемтәләрен алга таба үстерүгә ярдәм итә, дәүләтләр һәм халыкларның үзара ышанычын ныгытуга үзеннән өлеш кертә», – диде Фәрит Мөхәммәтшин.

Язучы фикере

Тишек турында фәлсәфә

Тавыкларга он итеп тартып бирү өчен борчак алып кайтырга кирәк иде. Бик файдалы икән ул, әллә ни кыйбат та тормый икән. Бер капчык алдым да киттем. Ярты юлга җиткәндә генә теге капчыкның тишек икәнен күрдем. Ерак җир булмаса да, кире борылып тормадым, ни әйтсәң дә, тишек – тишек инде ул, ертык түгел. Тишегә дә кечкенә, бер борчак сыярлык кына. Бер борчак сыярлык нәрсә өчен кире борылып торасыңмыни?

Тормышның бер сәер гадәте бар... Әгәр син нәрсәгәдер карап: «Нигә кирәк инде бу миңа!» – дип кул селтисең икән, тормыш сиңа шул нәрсәнең ник кирәклеген мәңге онытмаслык итеп аңлата. Капчыкны өйгә алып кайткач, мин дә аңладым инде. Бер чиләк чамасы коелып калган иде. Менә монысын колагыгызга киртеп куегыз: бер борчак сыешлы тишектән бер генә борчак коелмый.

Моны тормыш фәлсәфәсе итеп, төрле өлкәләргә күчереп, мисаллар китерергә мөмкин. Аеруча татар дөньясыннан, чөнки без – күпмедер дәрәҗәдә эрерәк халык, вакланырга яратмый торган. Әйтик, татарча язулардагы хаталарга да игътибар итмибез. Бер халыкның да, мәсәлән, интернеттан «хикәяләр», «җырлар», «мәктәп» дип әйбер эзләгәне юк. Татар фәкать шулай гына эзли. Эзләүчеләр таба алсын өчен дип, мин кайчагында үз сайтымда да сүзләрнең шундый вариантын кулланырга мәҗбүр булам. Дөрес итеп, әйтик, «хикәяләр» дип язсаң, таба алмыйлар. Чөнки укырга яратучы халык «хикәялэр» эзли. Элмә такталарда, урам исемнәрендә шул ук хәл. Хәтта безнең үз исем-фамилияләребез дә шундый ук хаталар белән языла. Ә без төзәтергә тырышмыйбыз, шуның белән вакланып йөрергә вакыт та, теләк тә юк.

Бу мисалларны санап китсәң, кәгазь җитмәскә мөмкин. Шуңа да вак-төяк нәрсәләр бит инде алар, капчыктагы борчак бөртекләре шикелле. Без берсенә дә игътибар итмибез, вакчыл булмаска телибез, ә асыл кыйммәтләр акрынлап кына коела бара...

Әгәр берәрсе дәшми-тынмый гына минем теге борчак капчыгыннан берәр чиләк тутырып алып китәргә теләсә, мин аңа бирмәс идем. Беркем дә бирмәс иде. Караклык яки талау бит инде бу. Хәтта кайтканда капчык умырылып, берәр җирдә берәр чиләге коелса, туктап җыеп алыр һәм ертылган җирен ямап куяр идем. Ә болай... Берни дә кылып булмый.

Бу бөтен өлкәдә дә, бөтен халыкта да шулай. Сәламәтлек тә. Без төчкерүләргә, баш авыртуларга, вак-төяк сызлануларга игътибар бирмибез һәм бер мәлне капка төбенә килгән ашыгыч ярдәм машинасына чыгып утырабыз. Гаилә тормышы да. Тормыш юлдашыбызның вак-төяк канәгатьсезлеген ишетмибез, аны кечкенә наздан, игътибардан мәхрүм итәбез һәм бер мәлне ярык тагарак өстенә утырып, баш ватабыз: «Ничек шулай килеп чыкты соң әле?» Ил тормышы да. Җитәкчеләрнең печтек кенә хаталарына, кечкенә гөнаһларына күз йомып яшибез-яшибез дә көрчеккә килеп терәлгәч, күзебез ачыла, фаҗигане аңлый, упкынны күрә башлыйбыз, әмма котылу юлы гына хилафлыклар күләгәсенә күмелгән була. Бәхет тә. Гомер дә. Барысы да.

Бу дөньяда әһәмиятсез бер генә нәрсә дә юк. Бер генә гамәл дә нәтиҗәсез тәмамланмый. Бер генә нәрсәгә дә вaклык итеп карарга ярамый. Дөнья зур, әмма ул вак кына кисәкчәләрдән тора. Моны барыбыз да беләбез инде.

Беләбез... Ә белем безгә нәрсә өчен кирәк? Шуның нәтиҗәсендә тормышыбызны җайлау, яхшы гамәлләр кылу өчен түгел. Белем безгә болай эшләргә ярамаганын яхшы төшенеп, бик акыллы кыяфәт белән хаталану өчен кирәк. Чөнки кешелекнең хәтер капчыгында да тишек бар бугай. Бер борчак сыешлы гына.

Марат КӘБИРОВ

Әйтеп кенә бактым

Нәрсә инде бу, җә!

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

Редакция урнашкан бинаның беренче катында кафетерий сыман нәрсә эшли башлады. Хуҗасы – Алия исемле сөйкемле, чибәр генә яшь ханым. Алиянең шундый кафетерийлары тагын икәү икән. Берүзе өчкә бүленә алмый бит инде, шуңа күрә безгә чәй-каһвә эчертергә яшь кызлар тапкан.

Әмма беркөнне иртән кызлар урынында кап-кара егетне күрдем. Ак тешләрен ялтыратып кергән бер кешегә: «Здравствуйте!» – дип дәшә. Каһвә өстәле ягына минем аяк тартмады. Юкса әлеге кара егетнең кем икәнен дә белмим. Бәлки, ул үзенең кешелек сыйфатлары буенча күпләрне көнләштерерлек егеттер.

Әбәд вакытында беренче катка төштем дә ишек төбендә торган сакчы егет Андрейдан: «Бу егет кулыннан чәй, каһвә эчүчеләр күп булдымы?» – дип сорадым. «Раз, два и обчелся», – ди бу. Егетне кызгана башладым. Әмма бу хис ничек башланса, шулай туктап кала иде. Нәрсә инде бу, җә? Без бит балачактан «антисемитизм», «нацизм», «расизм» дигән сүзләрне ишетеп үскән буын. Без, үз чиратыбызда, тән төсенә карап кеше рәнҗетүчеләргә ләгънәт укый идек. Ә менә бүген күмер кебек кап-кара малайга ничектер үзем дә шикләнеп карап торам. Нинди юләр хисләр саклана икән минем күңелдә, җә? Белүемчә, расизм XIX–XX гасыр башында Европаның, Америка континентының күп кенә илләрендә тыелган иде. Әмма узган гасырның утызынчы елларында Германиядә хакимлеккә национал-социалистлар килгәч, бу ил «чиста раса җире» дип игълан ителде һәм «раса гигиенасы» уздырыла башлады. Гади генә әйтсәк, «ариец»лардан башка бар халыклар «тулар-тулмас» саналып, аларны бетерү максат итеп куелды.

«Ариец» дигән төшенчә дә, андый раса да хәзер бөтенләй телгә алынмый. Андый милләт юк та ул. «Ария» – борынгы һинд сүзе һәм «лаеклы», «затлы», «хөрмәтле» дигән мәгънәне аңлата. Алман нацистлары да үзләрен иң затлы, хөрмәтле санап, башкаларны, бигрәк тә яһүдләрне һәм славян халыкларын эзәрлекли башлаганнар, ягъни алар яшәргә лаек түгел дип. Бүгенге Украина милләтчеләре дә тач шул эзгә басты.

Инде менә бер атнадан артык вакыт узгач, бу егет белән якыннан танышырга уйладым. Исемен сораган идем: «Ислам», – ди бу. Согуд Гарәбстаныннан икән. Ялгышлык белән: «А почему такой черный? Арабы обычно чуть светлее», – дип ычкындырдым. Ә ул: «Есть и чернее меня», – ди. Тән төсенә бәйләнүемә үпкәләмәде тагын. Ап-ак тешләрен күрсәтеп елмайды да: «А я – татарин», – дип куймасынмы?! Әле: «Исәнмесез!» – дип тә өстәде.

Ислам Казан халкы, аерым алганда, татарлар турында бик югары фикердә. Казан химия-технология институтында дүртенче курста укуын һәм шул дүрт ел эчендә безне тәмам белеп бетерүе белән мактанды. «Хороший народ у вас», – ди. Ялагайлану, ярарга тырышуга охшамаган. «Бәндә баласы үзен дошман күргән кешеләр арасында яши алмый», – ди Ислам. Мин: «Яшиләр бит әле», – дим. Мин русча әйттем, сәясәт турында бәхәсләшергә Исламның татарчасы җитеп бетми иде. Ә ул: «Яшиләр, ну сугышып яшиләр», – ди.

– Ә нигә? – мин әйтәм.

– Чөнки үзләренең кеше икәнлекләрен онытып җибәрәләр.

Гаҗәпләндерде Ислам мине. Ерак мәмләкәттән килеп Казанда гыйлем эстәүче, үз көнен үзе күрергә омтылып, буш вакытында каһвә сатучы, сәясәткә берниндн катышы булмаган кара тәнле бер егет бу дөньяда тату гына яшәп булуын әнә шулай гади итеп әйтте дә бирде бит.

Ә мин, карт җүләр, барыбыз да кеше икәнне онытып җибәргәнмен.

КАРАБАХ ТӨЕНЕН ЧИШКӘНДӘ

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

САКАЛЛЫ ФӘЛСӘФӘ

Без «Ватаным»да моннан ун көн тирәсе элек Таулы Карабах тирәсендә барган вазгыятьне шәрехләп: «Сизәсездер: зур сугыш уты кабыну ихтимал», – дип язган идек. Безнең ул фараз яртылаш тормышка ашты: 19 сентябрьдә Баку Карабахта әрмәннәр тарафыннан куелган минада 11 кеше шартлавын, Гәдәбәйдәге (Кедабек) азәрбайҗан позицияләренең утка тотылуын, Карабахтагы әрмәннәрнең пассажир самолетларына радиототкарлыклар ясавын сәбәп итеп, төбәктә конституцион тәртип урнаштыра башлавын игълан итте.

Азәрбайҗан армиясе, югары төгәллектәге технологик корал кулланып, сепаратистлар кулындагы һава һөҗүменә каршы көрәш системаларын, радиоэлектрон көрәш станцияләрен һәм башка бик күп төрле хәрби техниканы санаулы сәгатьләр эчендә юк итте. Баку бары тик хәрби объектларга гына һөҗүм ясавын, тыныч халыкның иминлегенә берни дә янамавын ассызыклый. Әмма үзегез аңлыйсыз инде: андый масштаблы һөҗүм вакытында югалтуларсыз булмый. Сепаратчылар бар көчләренә, тыныч халык үтерелә, дип сөрән салa, бу – көч җитмәгәнлектән, халыкара җәмәгатьчелек игътибары артына качуның бер ысулы гына. Автор һич кенә дә сугыш хәрәкәтләре яклы түгел. Ләкин хәл ут ачуга барып терәлгән икән, берни дә эшләп булмый, эшне мөмкин кадәр тизрәк һәм аз югалтулар белән төгәлләргә кирәк.

Укучыларга бер нәрсәне искәртер идем: бу юллар язылганда, утлы конфликтның башлануына бер тәүлек тә тулмаган әле, вазгыять тиз үзгәрә һәм язма газетада басылганчы, әллә ниләр булып бетәргә мөмкин. Сепаратчылар ут ачылып берничә сәгать үтүгә үк, сөйләшүләр өстәле сорадылар инде. Рәсми Баку табын җәяргә ризалыгын белдерде, ләкин әрмән радикалларына ак флаг күтәрергә, коралларны тапшырырга кушылды. Ул таләп үтәлсә, зур сөйләшүләр кирәкми дә. Өстенлек тулысынча Азәрбайҗан ягында. Әрмәнстан рәсми рәвештә сугыштан читтә калачагын белдерде. Ереван ярдәменнән башка төбәктәге әрмән армиясе (рәсми хакимиятләр Карабахта андый армия юк дип расларга тырышса да, ун меңлек контингент анда бар) берни дә эшли алмый. Әрмәннәрнең инде бик күп коралдан һәм техникадан колак кагуларын исәпкә алганда, сугыш озакка сузылмаска тиеш.

Язмада автор һич кенә дә сугыш хәрәкәтләренең хроникасын сөйләүне максат итеп куймый. Беренче залплар яңгыраган минутларда ук вакыйгалар урыныннан турыдан-туры дистәләгән хәбәр алынды һәм сугыш динамикасын шактый тәфсилле итеп сурәтләргә мөмкинлек бар. Безне башка нәрсә кызыксындыра. Игътибарыгызны язма башындагы «яртылаш тормышка ашты» дигән сүзләргә юнәлтер идем. «Ни өчен яртылаш, сугыш хәрәкәтләре тулы көченә бара бит инде?» – дигән сорау тумый калмагандыр дип уйлыйм. Эш шунда: Таулы Карабах аша күп сәяси мәнфәгатьләрнең бик зур тектоник плитәсе уза. Ул плитәнең хәрәкәте дөньякүләм зур тетрәү китереп чыгара ала. Әмма конфликтның башы андый тетрәү булмас дигән өмет уята. Гарантия биреп булмый булмавын, әмма Баку алдын-артын карап эш итә һәм зур селкенү ясарга теләгән көчләр кулында уен картасы юк. Без уен тузы Азәрбайҗан тарафдарлары кулында калыр һәм бу каршылыкның тиз хәл ителүенә китерер дип фаразлыйбыз.

Төбәктәге көчләр чагыштырмасын якынча сурәтлик. «Төркия, Азәрбайҗан һәм Пакыстан 18 сентябрьдән 30 сентябрьгә кадәр «Кардәшлек» дигән хәрби өйрәнүләр үткәрә, дигән кыска хәбәргә карыйк әле. Бакуның хәрби конфликтта уңышын гарантияләү өчен шул ике аркадаш җитә. Ләкин әле азәрбайҗаннарны принципиаль рәвештә тагын Израиль яклый. Бу сезгә бераз гаҗәбрәк тоелмыймы? Израиль Бакуны югары технологик корал белән тәэмин итә. Конфликтта бу хәлиткеч роль уйный. Киевка, мәсәлән, бу ил, Зеленский күпме генә ялвармасын, сыңар пуля да бирмәде, ә азәрбайҗаннарга – рәхим итегез. Әрмәнстан – Иран аркадашлыгы Израильне Баку тарафын сайларга мәҗбүр итә. Төбәктә бүген Тәһран – Ереванның бердәнбер диярлек аркадашы. Ни өчен мөселман фарсылар христиан әрмәннәрне яклый, ә азәрбайҗаннар белән этле-мәчеле яши дигән фикер уяна торгандыр. Шигыйләрнең, бигрәк тә аларның рафидит тармагының кемнәр икәнлеген яза башласак, газетада башка авторларга урын калмаячак. Шуңа күрә фактны гына әйтәбез: фарсылар әрмәннәр файдасына ут ачарга әзер. Ләкин Пакыстан һәм Төркия җәйгән канат Бакуны ул һөҗүмнән саклый. Чик буена фарсы гаскәрләре тезелсә тезелгәндер, әмма ут ачылмас. Берьялгызы калган Ереван Баку белән конфликта керүдән курка, чөнки җиңелү – котылгысыз.

«Татар-информ»

Россия традицион рәвештә Әрмәнстанны якларга тиеш иде, әмма Кремль алдан ук әйтеп куйды: Таулы Карабах – Азәрбайҗан төбәге, моны Пашинян үзе таныды, диде. Мәскәү Иран белән аркадашлыктан файдалана, билгеле, әмма Төркия белән әчелешле булырга Кремльдә юләрләр утырмый. Евросоюз Бакудан утны туктатуны таләп итте, әмма ут кызганда, андый сүзләргә игътибар итеп тормыйлар. Әрмәнстанны ачыктан-ачык Франция яклый. Бакуның Париж тарафына җавабы көттермәде: геноцид турында кычкырганда, үзеңнең кара үткәнеңне искә төшер, диделәр. АКШның симпатиясе әрмәннәр ягында, билгеле. Ләкин халыкара законнар Баку өстенлеген таный. Hudson Institute – Вашингтондагы йогынтылы аналитик үзәк: «Халыкара хокук Карабахны Азәрбайҗанныкы дип таный. Хәзерге моментта Азәрбайҗанның барлык хәрби хәрәкәтләре ил эчендә бара. Әрмәнстанга һөҗүм булмады», – дип белдерде.

Шулай булгач, кая барасың? Иң мөһиме: төбәктә башланырга мөмкин булган зур тектоник хәрәкәт булмас һәм афтершогы планетага таралмас дип өметләник. Тема БМО Генераль Ассамблеясында да күтәрелеп чыкты. Төрек Президенты Әрдоган үз чыгышында, Бакуны яклап, ныклы дәлилләр китерде. Франция Куркынычсызлык советын җыюны таләп итә, совет нинди генә карар кабул итмәсен, ул киңәш характерында гына булачак. Хәтта Иран да Таулы Карабахны Азәрбайҗанныкы дигән рәсми белдерү белән чыкты. «Карабах – әрмән төбәге түгел, шуңа күрә Ереван аны якламаячак», – дигән сүзләргә игътибар итегез әле. Алар Әрмәнстанның Куркынычсызлык советы секретаре Армен Григорян авызыннан телеэфирда әзелеп төште. Бу инде конфликтның яртылаш чишелүенә тиң.

shutterstock.com

ШӘРЫК ӘКИЯТЕ

Татарстанда чит илдә арзанлы ял тәкъдим итеп, халыкны сәфәрсез дә, акчасыз да калдырган ирле-хатынлы блогерлар тирәсендәге шау-шу кызганнан-кыза. Соңгы мәгълүматларга караганда, зыян күрүчеләр саны 800 кешегә якынлаша. Нәрсә бу? Безнең саксызлык һәм ваемсызлыкмы? Әллә халыкны төп башына утыртуның яңа ысулымы? «ВТ» хәбәрчесе әнә шул сорауларга җавап эзләде.

Бушлай сыр – тәбәдәме?

– Ирле-хатынлы блогерларны интернет аша моңа кадәр дә күреп белә идем, – ди Илусә һәм Раушан Миңнегалиевлардан Берләшкән Гарәп Әмирлекләренә тур сатып алган Гөлназ Шәрәфетдинова. – Илусәне социаль челтәрләр аша күзәтеп бардым. Үз-үзен тотышы, сөйләшүе белән баштарак ничектер ышаныч уятты ул. Өйләнешкәч, Дубайга күченделәр. Илусә дин юлына басып, яулык япты. Озак та үтмәстән, Дубайга сәяхәт турлары сата башладылар. Бәясе дә бик кызыктыргыч: бер кешелек ялны 10–15 мең сумга тәкъдим иттеләр. Монда юл да, яшәү дә, ашау да кергән. Өстәвенә яшәү урыны диңгезгә терәлеп тора. Кызыкмаган җирдән кызыгырсың! Диндәге кеше алдамас кебек тоелды. 13 июльдә бер кешегә 25 мең сумнан иремә, үземә һәм ике балабызга «Бакча туры» сатып алдым. Өйдә ял өчен түләргә артык акча булмаганлыктан, кредит рәсмиләштереп, күрсәтелгән банк картасына 100 мең сум акча күчердем.

Гөлназ Шәрәфетдинова сүзләренә караганда, ике арада бернинди килешү дә төзелмәгән. Илусә телефон номерын да бирмәгән хәтта.

– Аңа Россиядә тыелган социаль челтәр аша аралашу уңайлырак дип аңлатты. Чит илгә сәфәр 7–10 көн булачак, диделәр. Монысы бераз шик тә уятты, әлбәттә. Гадәттә сәяхәтнең ничә көнгә сузыласы төгәл билгеле була бит. Тик ял итәргә бару теләге зуррак иде, күрәсең. Артык төпченмәдем. Соңрак кына белдем: блогерлар алдан бернинди документ та бирми. Чыгып китәргә 1–2 көн кала гына бер якка билет җибәрәләр. Кире кайтканда да шул ук хәл. Тик билетлар көнендә үк булмаска да мөмкин. Шуңа күрә ял ун көнгә кадәр сузыла ала. Танышларыбыз август азагында блогерлар аша Дубайга барып кайтыгра өлгерде. Бик ошады, диделәр. Ә миңа сентябрь башында Илусәдән озын хат килеп төште. Алардан тур сатып алган бөтен кешегә җибәргәннәр аны. Хаттан аңлашылганча, ял оештыручыларга каршы башланган «мәгълүмати һөҗүм» аркасында, Дубайга сәфәр кичектереләчәк. Кайчанга кадәр икәне төгәл билгесез. Әле бер дата, әле икенчесен атадылар. Инде бу көннәрдә блогерлар тирәсендә барыбызга да билгеле ыгы-зыгы башлангач, акчаны кире кайтаруларын сорадым. Гариза язып җибәрергә куштылар. Тик акчаны киләсе елның 1 августына кадәр кайтарырга вәгъдә итте...

Тик акчаны киләсе елның 1 августына кадәр көтәсе, ди. Канун нигезендә, туроператор акчаны ун көн эчендә кире кайтарырга тиеш, дип таләп куя башлагач, минем белән, гомумән дә, элемтәгә чыгудан туктадылар. Россия Тикшерү комитетына, Икътисадый җинаятьләргә каршы көрәш идарәсенә гаризалар яздым. Тикшерүчеләр әле яңа гына шалтыратып, мәгълүмат сораштылар. Эш бара, димәк. Гаеплеләрне җаваплылыкка тартырлар, ә акчаны кире кайтарырлар дип өметләнәм.

Билгеле булганча, блогерлар аша Дубайда татар җәмәгатьчелегендә исеме танылган кешеләр дә ял итеп кайтты.

– Берләшкән Гарәп Әмирлекләренә тәүге тапкыр барыйбыз. Алты көн буе экскурсияләрдә йөрдек. Чүлдә дөяләргә дә утырдык, дөньядагы иң зур мәчетләрнең берсендә дә булдык. Ял бик ошады. Анда үзеңне киләчәк заманда кебек хис итәсең, – дип сөйләгән иде «ВТ» хәбәрчесенә җәй көне гаиләсе белән ялдан кайткач Салават Миңнехановы.

Тик андый бәхет һәркемгә дә тәтемәгән булып чыкты.

«Тота алмаслар дип уйлыйлардыр»

Танылган адвокат Руслан Нәгыев әйтүенчә, Миңнегалиевлардан зыян күреп, хокук саклау органнарына гариза язучылар саны көнләп түгел, сәгатьләп арта.

– Миңа узган атнада блогерлардан Берләшкән Гарәп Әмирлекләренә тур сатып алып, сәяхәтсез дә, акчасыз да калган бер төркем кеше мөрәҗәгать итте, – ди ул. – Биредә Россия Җинаять кодексының 159 маддәсенә («Мошенниклык») туры килүче җинаять билгесе күзәтелә. Ягъни сүз алдау яки кеше ышанычына керү юлы белән аның милкен урлау турында бара. Ике арада бернинди дә килешү төзелмәгән. Лицензия күрсәтүче дә юк. Һәрхәлдә, без бу хакта белмибез. Әйе, блогерлар социаль челтәрләрдә яңа алган лицензияләренең фотосын урнаштырган, ди. Әмма бу Берләшкән Гарәп Әмирлекләрендә экскурсияләр үткәрергә рөхсәт бирүче документ кына. Ә сәяхәт туры сату белән шөгыльләнү өчен лицензия булган очракта да, ике арада килешү төзү мәҗбүри. Монда исә акчаны шәхси затларга теркәлгән банк карталарына күчергәннәр дә, шуның белән шул. Зыян күрүчеләр узара берләштеләр инде. Социаль челтәрләрдә уртак төркемнәре бар, аралашып торалар.

Руслан Нәгыев «Телеграм» каналында алып барган соңгы саннарга караганда, зыян күрүчеләр исемлегендә 788 кеше исәпләнә. Зыян күләме 21 миллион 411 мең сумнан да артып киткән.

– Блогерлардан илнең төрле төбәкләрендә яшәүчеләр зыян күргән. Җинаять эшен Казан Эчке эшләр идарәсе тикшерәчәк дип уйлыйм. Чөнки гариза язучыларның күбесе Татарстан башкаласыннан. Күбесен блогерларның якташлары-быз булуы, өстәвенә баштагы яулык ышандырган. Турларның артык очсыз булуына шикләнеп караучыларны әтиәниләре: «Намаз укыган кеше алдашмый», – дип тә үгетләгән әле. Үзләре шулай ди. Бу хәлләр алдакчыларның акча өчен теләсә нәрсәгә әзер булуын тагын бер кат исбатлый. Аңлавымча, чит илдән, алдап булмаса йолдап, бөтен кешедән акча җыеп ятканнар. Дубайда үзләрен тота алмаячаклар дип уйлаганнар, күрәсең. Хәтта 1 сумга турлар тәкъдим иткәннәр. Башка сыймаслык хәл бит бу. Әлегә җинаять эше кузгатылмаган. Гаризалар узган атна ахырында килә башлады гына әле. Канун нигезендә җинаять эше кузгатырга ун көн вакыт бирелә. Хокук саклаучылар моңа кадәр дә, процессуаль тикшерү кысасында тур сатучыларны аңлатма бирергә чакыра ала. Килмиләр икән, үзләренә кыенга туры киләчәк. Җинаять эше кузгатылганнан соң, Россия аларны халыкара эзләү игълан итәргә һәм Берләшкән Гарәп Әмирлекләреннән әлеге затларны экстрадицияләүне сорарга мөмкин. Бу – вакыт таләп итә торган, әмма җайга салынган эш тәртибе.

Ундүрт меңлек түбә

Башкаладагы туризм агентлыкларының берсендә эшләүче Ангелина Саяпова әйтүенчә, сентябрь азагы – октябрьдә Дубайга бер атнага бер кешелек ял уртача 80–100 мең сумнан башлана.

– Ә блогерлар тәкъдим иткән бәягә күп дигәндә Сочи тирәсенә барып, бер атна ял итеп кайтып була. Бигрәк тә хәзерге заманда. Санкцияләр шартларында халыкка хезмәт күрсәтүче авиакомпанияләр саны кимеде. Туроператорлар юлламаларны кыйммәт бәягә сата дип зарланучыларга да шуны аңлатырга тырышабыз. Бу күктән алган саннар түгел. Ышанмасагыз, үзегез интернетка кереп тикшереп карый аласыз, анда бөтен мәгълүмат бар, – ди белгеч.

Шулай эшләдек тә. Блогерлар Дубай үзәгендәге Джумейра районында ял тәкъдим итә. «Авито» сайтында, мәсәлән, бу районда ике бүлмәле фатирны бер тәүлеккә арендага алып тору 10 мең сумнан башлана. Әнә Джумейра пляжыннан 400 метр ераклыкта, идәннән түшәмгә кадәр тәрәзәле, бөтен җиһазлары булган ике бүлмәле фатирны тәүлегенә 14 мең сумга тәкъдим итәләр. Кер дә яшә! Дөрес, ризык ягын үзең кайгыртасы була. Билет бәяләренә килгәндә, интернетта бу елларда Казаннан Дубайга бер кешегә иң арзанлы билетны 26 мең 257 сумга таптык. Туры рейс түгел. Грозный шәһәрендә икенче очкычка күчеп утырасы. Билет бәясенә багаж да кермәгән. Анысы өчен 5 мең сум тирәсе өстәп түлисе. Менә шуннан исәплә гез.

Мәсьәләгә ачыклык кертүләрен сорап, Илусә һәм Раушан Миңнегалиевларга да мөрәҗәгать иттек. Элемтәгә Илусә чыкты. «Интервьюны очрашкан очракта гына бирәбез. Берләшкән Гарәп Әмирлекләренә килегез. Журналистның без әйткән сүзне үзгәртү теләге тумасын өчен, интервью безнең тарафтан видеога төшереләчәк», – дип язды ул социаль челтәрдә. Кыек атып туры тидерделәр: ялга җыенган «ВТ» хәбәрчесенең кулында Дубайга юллама бар. «Бу атнада киләбез», – дигәч, кунакчыллык күрсәтеп: «Көтәбез, каршы алырга да әзер», – дип җавап бирде Илусә. Шуңа күрә бу сөйләшүгә нокта куелмады әле. Дубайда очрашканга кадәр!

Эльвира ВӘЛИЕВА

Чит илгә юллама сатып алганда нәрсәне истә тотарга?

Булат ЗАКИРОВ, «ВТ» юристы:

– Чит илдә ял итү еш кына туристик оператор аша оештырыла. Туроператор аша ял оештыру яхшы, чөнки алар күп эшне үз өстенә ала, ял итүчегә акчасын гына түлисе кала. Ләкин уяулыкны югалтырга ашыкмагыз: оператор белән сезнең өчен мөһим булган барлык сорауларны уртага салып сөйләшегез, килешү төзегез, аңа кул кую алдыннан, документны игътибар белән укыгыз. Сөйләшкәннәр кәгазьдә дә булсын. Әгәр дә сез ялыгыз туроператор гаебе белән бозылган дип саныйсыз икән, «Кулланучы хокукларын яклау турында» һәм «Россиядә туристлык эшчәнлеге нигезләре турында» законнар эшли. Үз хокукларыгызны дәгъва һәм суд аша якларга мөмкин.

Зөһрә САДЫЙКОВА

АКЧА ҖИМЕШЕ

АВЫЛ ХАЛКЫ ҮЗЕННӘН АРТКАННЫ НИЧЕК УРНАШТЫРА?

Акмаса да, тама, файдасы килеп тора. Үзеннән арткан сыйнигъмәтне район үзәгенә алып барып яки таныш-белешләренә сатучы авыл халкы әнә шулай ди. Кемдер итен, сөтен сатып акча эшләсә, кемдер яшелчә, гөмбә, себеркесен сатып табыш алырга тырыша. Бакча җимешен акчага әйләндерүнең нинди авырлыклары бар? Шул хакта белештек.

Өч ай тырышсаң...

Тырышлыгының чын әҗерен күреп гомер итүче Рәис Шәкүровны Арча районында белмәүчеләр сирәктер. Бакчасында мул уңыш алучы да, малларны симертү буенча рекорд куючы да ул. Без шалтыратканда да бәрәңгесен казып, аның уңышына чын күңелдән куанып йөргән вакыты иде. Бал, яшелчә, мунча себеркесе, мунчала кебек үз куллары белән әзерләгән продукцияне ул ел дәвамында Арчадагы махсус сату урынына алып барып урнаштыра.

– Моннан шактый еллар элек шәхси хуҗалыклар үз продукциясен сата алсын өчен Арчаның үзендә һәм станциядә махсус урын ясадылар. Хуҗалыгымда нәрсә бар, барысын да шунда алып барып сатам. Мин инде 30 ел дәвамында үзебездән артканны шулай урнаштырам. Арчага һәр атнаның дүшәмбе, пәнҗешәмбе һәм шимбәсендә барам. Элек без күбәү идек. Хәзер өч кеше калдык. Минем сатар товарым бик күп. Бәрәңгебез дә, башка яшелчәләр дә бик уңа. Аларны кая гына куеп бетерәсең? Яшелчә, бал гына түгел, сөтен, каймагын, эремчеген, кортын – барысын да ясап сатабыз. Быел кыяр, помидор бик шәп уңды. Аны без иртә язда сата башлыйбыз. Хәзер менә соң өлгерә торган кура җиләге пешә башлады. Бакча җиләген, карлыган, чия ише җиләк-җимешне, итне өйдән генә килеп алып бетерәләр. Сарыкны башлата гына сатып алалар. Малны белеп тәрбияләгәч, яшелчә, җиләк-җимешне карап үстергәч, үзебезгә дә, башкаларга да җитә, – ди ул.

Күп саткач, әле җитмәсә, ел әйләнәсе эшләгәч, табышы да зурдыр инде Рәис абыйның. Ә аның исәпләгәне дә юк икән!

– Үз сатып алучыларыңны булдыру өчен беренче чиратта сыйфатлы товар җитештерергә кирәк. Шуңа күрә иң элек барысын да үзебез тәмләп карап, тикшереп алып чыгабыз. Инде шул еллар дәвамында үземнең сатып алучыларым артты. Кичтән үк шалтыратып, заказларын әйтәләр. Шуңа күрә сатарга аптырап йөргәнем юк. Елның өч аенда тырышып эшләсәң, калган айларда тамагың тук була, – диде ул.

Сүз уңаеннан

Быелның 23 сентябре Татарстанда Гошер көне дип игълан ителде. Һәр елдагыча, мөхтәсибәтләрдәге мәчетләр гошер сәдакасы итеп җиләк-җимеш һәм яшелчәләр кабул итә: бәрәңге, кәбестә, чөгендер, кабак, суган һәм башкалар. Аннары азыктөлек җыелмаларын аз керемле, мохтаҗ кешеләргә тапшыру оештырылачак. Гошер – сәдаканың махсус төре, ул мөселман кешесенең, үстергән уңышын җыеп алганнан соң, аның уннан берен мохтаҗларга бирүдән гыйбарәт.

Пенсиягә өстәмә

Башка районнарда да күрше-тирә, таныш-белеш, «ватык телефон» аша сатылудан калган товарны урнаштыру өчен махсус урыннар булдырылган. Әйтик, Азнакай шәһәрендә һәм районның Актүбә бистәсендә сентябрьдән алып май ахырына кадәр атнаның һәр шимбәсендә ярминкәләр оештырыла. Биредә теләгән һәр кеше үзенең продукциясен сата ала. Ярминкәгә азнакайлылар гына түгел, күрше Башкортстан авылларыннан да килүчеләр бар.

Сукаеш авылында яшәүче Фәридә Гәрәйшина әлеге ярминкәләрдә ел саен үзе үстергән чәчәкләрне һәм кәбестә сата.

– Мин күп итеп мультифлора хризантема чәчәген үстерәм. Менә хәзер аларның шаулап чәчәк ата торган вакыты. Чәчәкләрне Азнакайдагы ярминкәгә алып барып сатам. Моннан тыш, унике ел элек үземнең кәбестә сортын булдырган идем. Анысын да сатам. Язын орлыклар, чәчәк үсентеләре әзерлим. Сөт ала торган кешеләребез дә бар, тик алар күпчелек очракта өйдән алып китә.

Фәридә ханым әйтүенчә, мондый сату урыннарының авыл халкына ярдәме аз түгел.

> – Без бит инде өлкән яшьтәге кешеләр. Каядыр барып сатып йөри алмыйбыз. Ә болай безгә бик уңайлы. Минем кебекләр бик күп. Зур керем алабыз димим, ләкин 13 мең сум пенсиягә әйбәт кенә өстәмә килеп чыга. Продукциябезнең анализын бирсәк тә, урын өчен акча түләттермиләр, – диде ул.

«Зарланып булмый»

Саба районындагы агросәнәгать комплексы хезмәтчәннәренең профсоюз рәисе Гөлназ Нигъмәтҗанова әйтүенчә, район халкы үзе җитештергән, үстергәнне күпчелек очракта гошер сәдакасы итеп бирә.

– Моннан тыш, сентябрьдән алып декабрьгә кадәр ике атнага бер тапкыр Казанның Агросәнәгать паркына барып сату мөмкинлеге бар. Анда ит һәм ит продуктлары, ашлык, бәрәңге, сөт һәм сөт ризыклары сатуга куела, – диде ул.

Байлар Сабасындагы «Аргамак» мәйданында да төрле продукцияне сатарга мөмкин. Монда зур йөк машиналары белән килеп, печән, ашлыкларга кадәр сатыла.

Алабуга районының Татар Дөм-Дөме авылында яшәүче Гөлнур Сәлимгәрәева шактый продукциясен өеннән генә сатып җибәрә, тик күпчелеген урнаштырыр өчен Чаллы базарына йөри. Биредә ул сарымсак, гөмбә, чи һәм тозланган, маринадланган яшелчәләр, үләннәр, себерке сата.

Илдар Мөхәммәтҗанов

– Безгә базар янындагы бер территориядә урын бирелә. Килешү төзеп, акча да түлибез. Биредә мин 2011 елдан бирле сату итәм. Элеккеге елларда, ирем исән вакытта, дүшәмбедән кала һәр көнне бара торган идем. Хәзер төрлечә була, тик атнасына бер-ике көн тәгаен барам. Мин гөмбәсен дә, башкасын да бик күп әзерлим. Өйдән генә берничек тә сатып бетереп булмый. Аннан соң, кеше белән аралашып, күрешеп кайту да күңелгә рәхәтлек бирә. Бер барганда барысын да сатып бетереп булмаса да, күбесен алалар. Мин бик канәгать, зарланып булмый, – диде Гөлнур Сәлимгәрәева.

Штраф юк

Россельхознадзорның Татарстан буенча идарәсендә дәүләт ветеринар тикшерүе булеге җитәкчесе Идрис Гатин әйтүенчә, республиканың бер генә шәһәрендә дә тиеш булмаган урыннарда сату итүче кешеләргә штраф салганнары юк.

– Профилактика максатыннан гына кисәтү ясый алабыз, – диде ул. – Безнең инспекторларның беркетмә төзергә рәхсәте юк. Билгеле, җәйге челләдә ит, сөт продуктлары саткан кешеләрнең документларын тикшерәбез, кирәк дип тапсак, кисәтү дә ясала. Ләкин үзеннән арткан яшелчә, җиләк-җимеш, чәчәк, кайнатма саткан өлкән яшьтәге кешеләргә штраф салу дигән нәрсә юк, – дип аңлатты ул.

Белгеч аңлатуынча, зур шәһәрләрдәге базарларда ветеринар-санитар лабораторияләр эшли. Сатучылар анда көн саен анализ бирергә тиеш. Сату мәйданнарына килгәндә, республика Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсеннән алынган мәгълүматлар буенча, алар 17 сату ноктасын контрольдә тота.

– Ләкин без яшелчәләрне түгел, ә ит ризыкларын тикшерәбез, – дип аңлаттылар идарәдә.

Уңышлы программа

Халык үзеннән арткан бәрәңге, яшелчәләрне авыл хуҗалыгы продукциясен әзерләү контораларына һәм кооперативларга да тапшыра ала. Татарстан кулланучылар җәмгыяте рәисе урынбасары Ренат Бикбов әйтүенчә, элеккеге әзерләү конторалары Алексеевск, Баулы, Сарман, Актаныш, Биектау районнарында сакланып калган. Ә Яшел Үзән, Питрәч районнарында халык үзләре үстергән яшелчәләрне яңа оешкан кооперативларга тапшыра ала. Алар исә үз чиратында яшелчәләрне көзге һәм язгы ярминкәләрдә сата. Билгеле булганча, Татарстанда шундый 14 сату ноктасы бар.

– Безнең автокибетләр авылларга һәрдаим йөреп тора. Гадәттә, яшелчәләрне шулар белән алып кайталар, – диде Ренат Бикбов.

Алексеевск районының кулланучылар җәмгыяте идарәсе рәисе Илнур Хәйбуллин әйтүенчә, әлеге программа халыкка кирәклеген раслаган.

– Без берничә ел дәвамында язын авыл халкына һәм мәктәпләргә кәбестә үсентеләре, кишер, чөгендер һәм суган орлыкларын бушлай таратабыз. Һәм көзен әлеге яшелчәләрне хуҗалыклардан җыеп алырга тырышабыз. Миңа калса, бу – республика өчен бик кирәкле программа. Халыктан сатып алынган яшелчәләрне ярминкәләргә алып чыгабыз, – диде ул.

Илнур Хәйбуллин әйтүенчә, халыктан 12 төрле яшелчә җыеп алалар. Быел районның кулланучылар җәмгыятенә 15 тонна бәрәңге, 10 тонна кишер, 8 тонна чөгендер, 5 тонна суган һәм кәбестә тапшырган.

– Халык башлыча кишер, кызыл чөгендер, бәрәңге, суган, кабак алып килә. Бернинди мәҗбүриләү юк. Теләге булганнар үзләреннән артканны гына тапшыра. Зур бакчаларда яшелчә үстерүче кешеләр бераз булса да акча эшләп калырга тырыша. Әйтик, без алардан бәрәңгене 16 сумга сатып алабыз да ярминкәдә 18 сумга тәкъдим итәбез. Кишерне 15 сумга алып, 17 сумга сатабыз. Монда үзебезгә файда эшләү турында сүз бармый, әлбәттә. Бәя аермасы транспорт чыгымнарына тотыла, – ди Илнур Хәйбуллин.

29 сентябрьдә сәгать 10нан 12гә кадәр сезнең белән элемтәдә журналист **Чулпан ГАРИФУЛЛИНА** була. Сорауларыгызны, әйтер сүзләрегезне 222-09-75 номеры буенча җиткерергә мөмкин.

ХАЛЫК АВАЗЫ

Җирне ничек кайтарырга?

Күршеләрем ике арадагы койманы яңартты. Азрак безнең кишәрлеккә дә кергәннәр. Тыныч кына сөйләшүләрнең файдасы булмады. Мескен хәлдә дә каласы килми. Хокукларымны ничек якларга икән?

Галимулла САБИТОВ.
Чаллы

Галина Галиуллина, Росреестрның Татарстан бүлеге матбугат җитәкчесе:

– Ни кызганыч, мондый хәлгә төшкән кешеләр бихисап. Күбесе, озакка китә, кыйммәткә төшә дип, артыннан да йөреп тормый. Нәрсәдән башларга да белмиләр: берәүләр суд юлын таптый, икенчеләре участковыйга йөгерә.

Мондый очракларда Росреестрның Татарстан бүлегенә мөрәҗәгать итәргә кирәк. Ничек кенә булмасын, күршегез тәртип бозган, ягъни чикне үтеп кергән бит. Дәшми калырга ярамый. Әмма бу очракта әлеге участокка Күчемсез милекнең бердәм реестрында хокукларыгыз теркәлгән булырга тиеш. Бары тик сезнең милек икәнен раслаган документлар булган очракта гына җирегезне кире кайтарырга мөмкин.

Росреестрның Татарстан бүлегенә гаризаны язмача да, Россия дәүләт хезмәтләре порталыннан электрон почта аша да җибәрергә ярый. Үзең килеп бирергә дә мөмкин. Адресны һәм телефон номерларын Росреестр сайтыннан табарга була. Мөрәҗәгатьтә җир кишәрлегенең адресын һәм кадастр номерын, койма күчерелү нәтиҗәсендә хокукларыгыз бозылу турындагы мәгълүматны күрсәтергә кирәк.

Сезнең гаризага нигезләнеп, җирдән файдалану һәм саклау буенча дәүләт инспекторлары тикшерү үткәрәчәк һәм Россия законнарына нигезләнеп, чаралар күрәчәк.

Безгә ник арттырмыйлар?

Хәзер 80 яшь тулган кешеләргә пенсияне 15 мең сум күләмендә өстиләр икән. Без сугыш чорында эшләдек, инвалид калдык. Бу өстәмәне дә 6 ел элек 6 мең сум тирәсе биргәннәр иде. Һаман шул килеш калды. Ник безгә дә өстәмиләр икән аны?

Рәйханә НУРИЕВА.
Казан

Софья Комарова, эксперт:

Рәйханә ханым дөрес аңлап бетермәгән. Эш болайрак. Лаеклы ялга чыкканда бирелә торган иминият пенсиясе ике өлештән тора: үзгәрми торган һәм тупланма өлешләр. Үзгәрми торган дип саналса да, ул бераз артып тора. 2023 елда үзгәрми торган өлеш 7 мең 567 сум 33 тиен күләмендә билгеләнгән. 80 яшь тулгач, үзгәрми торган өлешкә шушы ук күләмдә өстәмә кушыла. Әмма мондый хәл кеше гомерендә бер тапкыр гына – 80 яше тулгач кына була. Шулай итеп, 80 яшьлек кеше өчен үзгәрми торган өлешнең гомуми суммасы 15 мең 134 сум 66 тиенгә җитә. Аңлашылганча, өстәмәнең күләме 7 мең 567 сум 33 тиен генә тәшкил итә.

Илдар Мөхәммәтҗанов

2024 елның 1 гыйнварына пенсиянең үзгәрми торган өлеше 8 мең 182 сум 17 тиен булачак. Димәк, пенсия күләме автомат рәвештә артачак. 80 яшен тутырган пенсионерларга да гариза язарга кирәкми. Әмма, шунысын да әйтергә кирәк, мондый өстәмә бары тик картлык буенча иминият пенсиясе алучыларга гына киләчәк. Инвалидлык һәм туендыручысын югалту буенча социаль пенсия алучыларга бу кагылмый. Өлкән яшьтәге кешеләр, файдалы булса, пенсия төрен алыштыра алалар. Әгәр 80 яшьлек кеше рәсми төстә эшләвен дәвам итсә, өстәмә дә тулысынча бирелми, чөнки эшләүче пенсионерларның пенсиясе индексацияләнми.

Радио кая киткән?

Безнең авылда нишләптер «Татарстан» дәүләт радиосы тотмый. Югыйсә «Татар радиосы»н да, «Болгар»ны да, «Тәртип»не дә рәхәтләнеп тыңлыйбыз. Дәүләт радиосын да тыңлыйсыбыз килә, нишләргә кирәклеген белмибез.

Вакыйф ФАТЫЙХОВ.
Мамадыш районы
Югары Олыяз авылы

Редакциядән. Вакыйф абыйның үтенече буенча без Мамадыш районы хакимиятенең матбугат җитәкчесе Гөлназ Кадыйровага шалтыраттык. Ул мәгълүматларны язып алды. «Сәбәбен тикшереп, Вакыйф абыйга ярдәм итәрбез», – дип вәгъдә бирде.

Көз көне күпме су сибәргә?

Көз көне агачларга су сибәргә кирәклеген беләбез. Әмма аны күпме һәм кайчан сибәргә икән?

Фазулла ГАЙНЕТДИНОВ.
Казан

Роза Михайлова, һәвәскәр бакчачы:

– Эссе җәйдән соң, сентябрьдә, агачларга һәм куакларга күп итеп су сибәләр. Бу – кышка әзерләнгәндә мәҗбүри эш. Агачлар һәм куаклар астында туфрак метр ярым тирәнлеккә кадәр чыланырга тиеш. Шуңа күрә агач төбенә тишем ясарга кирәк, су тирәякка таралмыйча, шунда төшсен. Яшь агачларга һәм куакларга 40–50 литр, зурларына 60–70 литр су кирәк. Агачларга суны яфракларның күп өлеше коелып беткәч кенә сибәләр.

Юллама кайчан булыр?

Миңа 72 яшь. Элек һөнәри авырулар буенча һәр ел шифаханәгә юллама бирәләр иде. Аны бетерделәр. Колак аппараты белән дә шул ук хәл. Нишләп барысын да туктаттылар икән?

Ринат МӨХӘРЛӘМОВ.
Биектау

Елена, Дәүләт социаль иминият фонды белгече:

– Беренче чиратта сорау бирүче кешенең шәхси тернәкләндерү программасы бармы-юкмы икәнлеген белергә кирәк. Булган очракта ул табибка мөрәҗәгать итәргә тиеш. Анда юллама тиешме-юкмы икәнлеген ачыклыйлар, табигый шартлар буенча нинди шифаханәдә ял итәргә кирәклеген тәгаенлиләр. Табиблар биргән белешмә белән Ринат абый Социаль иминият фондының территориаль бүлекчәсенә, ягъни Биектау районына мөрәҗәгать итә ала. Белешмәләр өчен контакт үзәге телефоны: 8-800-1-00000-1.

Кибет төзергә мөмкинме?

Шәхси торак төзелеше өчен билгеләнгән җир участогына кибет төзергә мөмкинме?

Сәвия АБЗАЛОВА.
Минзәлә

Булат Закиров, "ВТ" юристы:

– Әйе, үз милкең булган җирдә кибет төзергә була. Әмма моның өчен гамәлдәге законнар нигезендә участокны башка максатларда файдалану өчен үзгәртергә кирәк. Мәсәлән, сезнең җир кишәрлеге берәр торак пунктта, анда шәхси йорт төзергә рөхсәт ителгән, ди. Җирдән файдалану кагыйдәләре буенча әлеге участокта кибет кебек объектлар төзергә ярaса, рөхсәт алыр өчен муниципаль берәмлекнең башкарма комитетына мөрәҗәгать итегез. Кагыйдәләр турындагы мәгълүмат башкарма комитетның рәсми сайтында урнаштырылган. Документ алгач, гариза язып, күпфункцияле үзәк аша Росреестрның Татарстан бүлегенә мөрәҗәгать итәргә кирәк.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА әзерләде

Укучы сүзе

Үзебезчә ял иттек

Азнакай районының Сәпәй авылы мәдәният йортында бик матур бәйрәмдә катнашып, авылда яшәүче абыйлар, апалар белән аралашып, илһам җыеп кайттым. Клуб мөдире Ләйсән Латыйпова очрашуга чакыргач, бик теләп килдем. Сәпәйлеләр – минем өчен үз кешеләр. Авыл җирлеге башлыгы да – авылдашым. Бу җирлектән минем иҗаттәш дусларым Марат Мозаффаров, Алмаз Закиров чыккан. Чарада иҗат юлымда төпле киңәшләре белән ярдәм иткән Әсгать абый Сәгытдиновның булуы икеләтә куанычлы булды. Сәпәйлеләр – бар яклап та булган халык. Мул итеп әзерләнгән чәй табыны да, көзге муллык күргәзмәсе дә – шуның ачык мисалы. Җырладык та, биедек тә, шигырьләр дә сөйләдек. Кыскасы, рәхәтләнеп ял иттек. Үзебезчә, авылча, дөнья мәшәкатьләрен кертмичә.

Гөлчәчәк
ХАҖИЕВА-САДРЕТДИНОВА

Кунакта

Кама Тамагы районының Олы Мәрәтхуҗа авылында Туфан абый Миңнуллин туып-үскәнлеген барыгыз да беләсездер инде. Олы Мәрәтхуҗа – кодагыемның да туган авылы. Туфан абый белән күрше булып яшәгәннәр. Шунда кунакта булып кайттык әле. Туфан Миңнуллинның туган нигезендә иҗат йорты, музей комплексы бар. Киленебез Роза безне чишмәләргә алып барып, ике матур күлне күрсәтеп, тарихларын сөйләп, таныштырып йөрде. Музейда кодагыйның бертуган сеңлесе Гөлнара музей саклаучы булып эшли. Икәүләп музейга, иҗат йортына экскурсия үткәрделәр. Рәхмәт яусын аларга!

Тик Олы Мәрәтхуҗа дип йөртелсә дә, авыл бик кечкенә хәзер. Барлыгы 40лап кына кеше яши икән. Яшьләр юк та юк инде. Авылның киләчәге менә шул музей комплексына туристлар җәлеп итүгә бәйле булса гына. Авылны иңләп озак йөрдек без. Урамда бер генә кешене дә очратмадык.

Римма ЯРУЛЛИНА. Баулы

25 сентябрь | Дүшәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 16+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 Утренняя программа «Здравствуйте!» 16+
10.00, 16.30 «АК ЧӘЧӘКЛӘР». Телесериал 16+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
11.30, 16.00 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «ФРОНТ». Телесериал (татар телендә) 16+
13.00 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 16+
14.00 «Закон. Парламент. Общество» 16+
14.45 «Семь дней+». Интервью с Рустемом Валиахметовым – директором Музея социалистического быта 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә». «Акыл батл» һәм «Учимся вместе» 0+
17.30 «Трибуна «Нового Века» 16+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Туган авылым» 12+
21.00 «Заман көзгесе» 6+
23.00 «В ОДНУ РЕКУ ДВАЖДЫ». Телесериал 16+
00.00 «Соотечественники» 16+
00.25 «Каравай». Национальные традиции, воплощенные в живописи и природе 6+
00.50 «Таяну ноктасы» 16+
01.15 «Кичке аш» 16+
02.05 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 16+
03.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлар белән) 16+
04.45 «Точка опоры» 16+
05.35 «Оныта алмыйм...» Ретро-концерт 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара». Мәгълүмати- күңел ачу программасы 16+
08.00 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.40, 18.20, 23.10, 04.20 «Башваткыч» 12+
09.50 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 16+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30 «Туган җир» 12+
12.05 «Йөрәктән – йөрәккә». Хәлил Әбҗәлилов турында телеочерк 16+
15.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
16.30 «Заман көзгесе» 6+
17.00 «Сәләт» 16+
17.30 «Адымнар» 16+
19.10, 22.10 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
19.30 «Әниемнең җылы кочагы» 16+
20.30, 02.40 «Таяну ноктасы» 16+
21.25 «Калеб» 6+
21.55 «Туган авылым» 12+
00.15 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
00.40 «Ватандашлар» 16+
03.05 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.30 «Йөрәктән – йөрәккә». Хәлил Әбҗәлилов турында телеочерк 16+
05.10 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 16+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Премьера. «Давай поженимся!» 16+
16.05 «Мужское/Женское» 16+
17.00 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.30 Информационный канал 16+
19.55 Премьера. «Куклы наследника Тутти» 16+
21.00 «Время»
22.00 Премьера. Ольга Сутулова, Кирилл Кяро. «СПРОСИ МАРТУ» (S) 16+
22.55 «Большая игра» 16+
23.55 ПОДКАСТ.ЛАБ «Гори огнем» 16+
00.40 ПОДКАСТ.ЛАБ «Пусть не говорят, пусть читают» 16+
01.20 ПОДКАСТ.ЛАБ «20 лет спустя» 16+
02.00 ПОДКАСТ.ЛАБ «Психика» 16+
02.40 ПОДКАСТ.ЛАБ «Космические истории» 16+
03.00 Новости
03.05 ПОДКАСТ.ЛАБ «Космические истории» 16+
03.20 ПОДКАСТ.ЛАБ «Антропология» 16+
03.55 ПОДКАСТ.ЛАБ «Обязательно к прочтению» 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 Премьера. «Наши» 12+
16.30 «Малахов» 16+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Премьера. Игорь Петренко, Александра Никифорова, Ольга Красько, Александр Ратников. «ДОКТОР КРАСНОВ» 16+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.05 Анна Ковальчук в детективном телесериале. «ТАЙНЫ СЛЕДСТВИЯ» 12+
03.50 Детективный телесериал «МОРОЗОВА» 16+

МАТЧ ТВ

06.00, 14.00 «Игра миллионов» 12+
06.30 «Всё о главном» 12+
07.00, 09.35, 12.20, 14.50 Новости
07.05, 14.55, 22.15 Все на Матч! Прямой эфир
09.40, 14.30, 02.40 Специальный репортаж 12+
10.00, 21.15 Футбол. МИР Российская Премьер-Лига. Обзор тура 6+
11.00 «Есть тема!» Прямой эфир
12.25 Бокс. Bare Knuckle FC. Лоренцо Хант против Криса Камоцци. Трансляция из США 16+
15.25 Хоккей. Фонбет Чемпионат КХЛ. «Сибирь» (Новосибирск) – «Динамо» (Москва). Прямая трансляция
17.45 «Громко». Прямой эфир
18.45 Хоккей. Фонбет Чемпионат КХЛ. «Нефтехимик» (Нижнекамск) – «Барыс» (Астана). Прямая трансляция
23.05 Смешанные единоборства. UFC. Рафаэль Физиев против Матеуша Гамрота. Трансляция из США 16+
00.35 «Вы это видели» 12+
01.05 Триатлон. Мировая серия. Финал. Мужчины. Трансляция из Испании 0+
02.35 Новости 0+
03.00 Волейбол. Кубок столетия. Финал 4-х. Женщины. Финал. Трансляция из Новосибирска 6+
05.00 Гребля на байдарках и каноэ. Чемпионат мира. Слалом. Трансляция из Великобритании 0+

НТВ

04.50 Сериал «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25, 10.35 «ПЁС» (S) 16+
13.30 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» 16+
17.50 «ДНК» 16+
20.00 «ПЕРВЫЙ ОТДЕЛ» (S) 16+
22.15, 00.00 Премьера. Сериал «НАПАРНИКИ» (S) 16+
00.55 Сериал «А.Л.Ж.И.Р.» (S) 16+
03.25 Сериал «ГЛАЗА В ГЛАЗА» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «6 кадров» 16+
06.45 «По делам несовершеннолетних» 16+
07.35 «Давай разведёмся!» 16+
08.35 «Тест на отцовство» 16+
10.45 «Понять. Простить» 16+
11.55 «Порча». «Он предвидел смерть». «Домовой» 16+
13.00 «Знахарка» 16+
13.35 «Верну любимого» 16+
14.10 «Голоса ушедших душ» 16+
14.45 «Преступления страсти» 16+
19.00 «МАМА ВСЕГДА ПРАВА» 16+
23.05 «Понять. Простить» 16+
00.10 «Порча» 16+
01.05 «Знахарка» 16+
01.30 «Верну любимого» 16+
02.00 «Голоса ушедших душ» 16+
02.25 «Тест на отцовство» 16+
04.05 «Преступления страсти» 16+
05.40 «6 кадров» 16+
05.45 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

05.05 «ЗЕМЛЕТРЯСЕНИЕ» 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 17.00, 19.00 Новости дня 16+
09.15, 21.00 «Открытый эфир». Ток-шоу 16+
11.00, 01.15 «ВОЗВРАЩЕНИЕ РЕЗИДЕНТА». 1-я серия 12+
12.35, 13.25, 15.05, 03.40 «НОЧНЫЕ ЛАСТОЧКИ». Телесериал. 1-я и 2-я серии 16+
15.00 Военные новости 16+
15.20, 17.15 «НОЧНЫЕ ЛАСТОЧКИ». Телесериал. 3-я и 4-я серии 16+
18.00 «Битва оружейников». Документальный сериал. «ПВО ближнего действия. 2С6 «Тунгуска» против LAV-AD «Блейзер». Премьера! 16+
18.50 «Специальный репортаж» 16+
19.55 «По горячим следам» 16+
20.10 «Ищу своих». Премьера! 12+
22.45 «Между тем» 12+
23.15 «ВОР» 16+
02.20 «Нюрнберг». Документальный сериал 16+

26 сентябрь | Сишәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара» 16+
07.00, 18.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
10.00, 16.30 «АК ЧӘЧӘКЛӘР». Телесериал 16+
11.00 «Фолиант в столетнем переплёте». К 100-летию А.Н.Островского 16+
11.15 «Если хочешь быть здоровым». Ковид, инсульт, инфаркт 16+
11.30, 16.00 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «ФРОНТ». Телесериал (татар телендә) 16+
13.00 «Туган җир» 12+
13.30 «Юлчы» 16+
14.00 «Путь» 16+
14.15 «Не от мира сего...» 16+
14.45 «Семь дней+». Интервью с акушером, заслуженным врачом РТ Ильдаром Фаткуллиным 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Төймә» һәм «Учимся вместе» 0+
17.30 «Казаннан – Казанга» 16+
18.00 «Таяну ноктасы» 16+
19.10 Хоккей. Чемпионат КХЛ. «Динамо» (Мн) – «Ак барс». Прямая трансляция 6+
22.00 «Вызов 112» 16+
23.00 «В ОДНУ РЕКУ ДВАЖДЫ». Телесериал 16+
00.00 «Видеоспорт» 16+
00.25 «Tatarstan today. Открытый миру» 16+
00.50 «Башваткыч» 12+
01.40 «Кичке аш» 16+
02.05 «Манзара» 16+
03.30 «Туган җир» 12+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлар белән) 16+
04.45 «Точка опоры» 16+
05.35 «Оныта алмыйм...» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара» 16+
08.00 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.40, 18.20, 23.10, 04.20 «Җырлыйк әле!» 12+
09.40 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
10.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30, 16.30, 20.30, 02.40 «Таяну ноктасы» 16+
12.05, 21.25 «Ком сәгате» 16+
15.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
17.00 «Музыкаль мәйдан» 16+
19.10, 22.15 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
20.00 «Халкым минем» 12+
00.15 «Тамчы-шоу» 6+
03.05 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.30 «Мин кайтырмын сезгә яңадан». Татарстанның халык шагыйре Фәнис Яруллин турында телеочерк 16+
05.10 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 16+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Премьера. «Давай поженимся!» 16+
16.05 «Мужское/Женское» 16+
17.00 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.30 Информационный канал 16+
19.55 «Куклы наследника Тутти» 16+
21.00 «Время»
22.00 Премьера. «СПРОСИ МАРТУ». Многосерийный фильм (S) 16+
23.00 «Большая игра» 16+
00.00 ПОДКАСТ.ЛАБ «Легкие деньги» 16+
00.45 ПОДКАСТ.ЛАБ «Эйзенштейн 125» 16+
01.25 ПОДКАСТ.ЛАБ «Собрались с мыслями» 16+
02.05 ПОДКАСТ.ЛАБ «Жизнь замечательных» 16+
02.45 ПОДКАСТ.ЛАБ «Все хотят летать» 16+
03.00 Новости
03.05 ПОДКАСТ.ЛАБ «Все хотят летать» 16+
03.25 ПОДКАСТ.ЛАБ «АстроУмные» 16+
04.00 ПОДКАСТ.ЛАБ «Произвольная программа» 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 Премьера. «Наши» 12+
16.30 «Малахов» 16+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Премьера. Игорь Петренко, Александра Никифорова, Ольга Красько, Александр Ратников. «ДОКТОР КРАСНОВ» 16+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.05 Анна Ковальчук в детективном телесериале «ТАЙНЫ СЛЕДСТВИЯ» 12+
03.50 Детективный телесериал «МОРОЗОВА» 16+

МАТЧ ТВ

06.00, 14.00 «Игра миллионов» 12+
06.30 «Наши иностранцы» 12+
07.00, 09.35, 12.20, 14.50 Новости
07.05, 14.55, 18.30, 23.45 Все на Матч! Прямой эфир
09.40, 14.30, 02.40 Специальный репортаж 12+
10.00 «Легендарные клубы» 12+
11.00 «Есть тема!» Прямой эфир
12.25 Смешанные единоборства. UFC. Джон Джонс против Энтони Смита. Трансляция из США 16+
15.55, 00.35 «География спорта. Республика Алтай» 12+
16.25 Футбол. FONBET Кубок России. «Уфа» – «Торпедо» (Москва). Прямая трансляция
19.15 Хоккей. Фонбет Чемпионат КХЛ. ЦСКА – «Северсталь» (Череповец). Прямая трансляция
21.40 Футбол. Чемпионат Италии. «Ювентус» – «Лечче». Прямая трансляция
01.05 Триатлон. Мировая серия. Финал. Женщины. Трансляция из Испании 0+
02.35 Новости 0+
03.00 Баскетбол. Единая лига ВТБ. Суперкубок. Финал 6+
05.00 Гребля на байдарках и каноэ. Чемпионат мира. Слалом. Трансляция из Великобритании 0+

НТВ

04.50 Сериал «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25, 10.35 Остросюжетный сериал «ПЁС» (S) 16+
13.30 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» 16+
17.50 «ДНК» 16+
20.00 Детектив «ПЕРВЫЙ ОТДЕЛ» (S) 16+
22.15, 00.00 Премьера. Сериал «НАПАРНИКИ» (S) 16+
00.55 Сериал «А.Л.Ж.И.Р.» (S) 16+
03.20 Сериал «ГЛАЗА В ГЛАЗА» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
07.25 «Давай разведёмся!» 16+
08.20 «Тест на отцовство» 16+
10.30 «Понять. Простить» 16+
11.35 «Порча». «Тут кто-то есть». «Останется только один» 16+
12.40 «Знахарка» 16+
13.15 «Верну любимого» 16+
13.50 «Голоса ушедших душ» 16+
14.25 «Твой Домашний доктор» 16+
14.40 «Преступления страсти» 16+
19.00 «НИКОМУ НЕ РАССКАЖЕМ» 16+
23.00 «Понять. Простить» 16+
00.05 «Порча» 16+
01.00 «Знахарка» 16+
01.25 «Верну любимого» 16+
01.55 «Голоса ушедших душ» 16+
02.20 «Тест на отцовство» 16+
04.00 «Преступления страсти» 16+
05.35 «6 кадров» 16+
05.50 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

05.15 «НОЧНЫЕ ЛАСТОЧКИ». Телесериал. 3-я и 4-я серии 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 17.00, 19.00 Новости дня 16+
09.15, 21.00 «Открытый эфир». Ток-шоу 16+
11.00, 01.05 «ВОЗВРАЩЕНИЕ РЕЗИДЕНТА». 2-я серия 12+
12.35, 13.25, 15.05, 03.40 «НОЧНЫЕ ЛАСТОЧКИ». Телесериал. 5-я и 6-я серии 16+
15.00 Военные новости 16+
15.25, 17.15 «НОЧНЫЕ ЛАСТОЧКИ». Телесериал. 7-я и 8-я серии 16+
18.00 «Битва оружейников». Документальный сериал. «Самоходные артиллерийские установки. 2С7 «Пион» против М110». Премьера! 16+
18.50 «Специальный репортаж» 16+
19.55 «По горячим следам» 16+
20.10 «Улика из прошлого» 16+
22.45 «Между тем» с Наталией Метлиной 12+
23.15 «ЗИМНИЙ ВЕЧЕР В ГАГРАХ» 12+
02.10 «СВИНАРКА И ПАСТУХ» 12+

КОТЛЫЙБЫЗ!

Гаилә институтын ныгытудагы һәм балалар тәрбияләүдәге зур казанышлары өчен **Хәнифова** Чулпан Минзаһит кызы, **Хәнифов** Иршат Хәниф улы Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә **«Ата-ана даны» ордены медале** белән бүләкләнде.

* * *

Эшендә ирешкән уңышлары һәм күпьеллык намуслы хезмәтләре өчен «АК БАРС» акционер коммерциячел банкы (гавами акционер җәмгыяте) Стратегия, инновация һәм маркетинг департаментының коммуникацияләр буенча директоры **Гулько** Елена Николаевна, Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт торак фондының мәгълүмат технологияләре бүлеге баш белгече **Садиева** Наилә Равил кызы, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «Мәгариф үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе баш бухгалтеры **Сәфәрова** Розалия Гыйльметдин кызы, «Челтәр компаниясе» акционер җәмгыяте генераль директоры ярдәмчесе **Хәсәншин** Равил Раиф улы, Татарстан Республикасының «Татлизинг» дәүләт унитар предприятиесе генераль директоры **Хафизов** Илнар Фәнил улы; халыкны социаль яклау өлкәсендәге казанышлары, актив иҗтимагый һәм хәйрия эшчәнлеге өчен «Ярдәм-Помощь» илкүләм хәйрия фонды президенты **Исмәгыйлев** Илһам Фәтхирахман улы; күпьеллык намуслы хезмәте һәм актив иҗтимагый эшчәнлеге өчен Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Дүсмәт авыл җирлеге башлангыч ветераннар иҗтимагый оешмасы әгъзасы **Степанов** Николай Степанович; республиканың дәүләт хакимияте органнарында күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Хокук идарәсе социаль законнар бүлеге мөдире урынбасары **Шаһиева** Лилия Габделбарый кызы Татарстан Республикасының **«Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

* * *

Татарстан Республикасының социаль-икътисадый потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүләре һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы хокук идарәсенең җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләрен хокукый яктан тәэмин итү бүлеге әйдәүче белгече **Авдеев** Дмитрий Алексеевич, «ДОМКОР» махсуслаштырылган торак төзүче оешма җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры **Гайнуллов** Мөнир Әнвәр улы, «Чулпан» иминият компаниясе акционер җәмгыятенең Алабуга филиалы Мамадыш вәкиллеге җитәкчесе **Иванов** Николай Петрович, «КАМАЗ-Автоспорт» коммерциячел булмаган партнерлыгы маркетинг һәм PR-коммуникацияләр бүлегенең маркетинг буенча баш белгече **Каблукова** Юлия Вениаминовна, хезмәт ветераны **Калмыкова** Галина Петровна, «Казан Экспо» конгресс-күргәзмә, мәдәни, тамаша-күңел ачу, спорт-массакүләм һәм социаль юнәлештәге чараларны үстерү һәм аларга булышлык итү үзәге» автоном коммерциячел булмаган оешмасы генераль директоры **Миңнегалиев** Роберт Хәмит улы, «Казан халык сәнгать һөнәрчелеге техникумы» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе укытучысы **Таһирова** Зөлфия Басар кызы, Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты су белән тәэмин итү һәм юынтык суларны агызу өлкәсендә тарифларны җайга салу һәм контрольдә тоту бүлеге әйдәүче киңәшчесе **Устинова** Ирина Александровна, хезмәт ветераны **Хөсәенов** Рәхимҗан Сабит улы, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының «Норма урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе китапханәчесе **Шакирова** Гөлшат Мөбарәкҗан кызы **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

* * *

«КАМАЗ» гавами акционер җәмгыяте логистика үзәгенең автокомпонентлар производствосы логистика департаментының планлаштыру бүлеге әйдәүче инженеры **Бавтюк** Розалия Гаптелхәй кызына, «Вакууммаш» акционер җәмгыятенең технология хезмәте серияле эшләнмәләргә хезмәт күрсәтү бюросы башлыгы **Калугина** Ольга Павловнага, «КАМАЗ-Автоспорт» коммерциячел булмаган партнерлыгының двигательләр эшләү һәм аларны кулдан төгәлләү бүлеге башлыгы **Кучев** Сергей Михайловичка, «РИМЕРА-АЛНАС» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте механика цехының санлы программа нигезендә идарә ителә торган станоклар көйләүчесе **Мефодьев** Юрий Семеновичка, «Казан моторлар төзү җитештерү берләшмәсе» акционер җәмгыятенең Зеленодольск машина төзү заводы филиалы фрезеровщигы **Рәхимов** Тәлгать Фоат улына, «КАМАЗ» гавами акционер җәмгыяте кою заводы чуеннан төгәл эшләнмәләр кою цехының чуен кою машиналары көйләүчесе **Самоявчев** Николай Сергеевичка, «КАМАЗ» гавами акционер җәмгыяте пресс-рам заводының эре штамповка цехы слесарь-инструментчысы **Усманов** Нәзир Әхмәдулла улына, «Вакууммаш» акционер җәмгыяте механика-җыю производствосының вак станоклар участогы токаре **Хузяхметов** Илгиз Вәлиәхмәт улына, «Казан вертолет заводы» акционер җәмгыяте хезмәте башлыгы **Черемисов** Александр Алексеевичка **«Татарстан Республикасының атказанган машина төзүчесе»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

«ТАНЕКО» акционер җәмгыяте генераль директорының техник хезмәт күрсәтү һәм инжиниринг буенча урынбасары хезмәтенең электр җиһазларына техник хезмәт күрсәтү һәм аларны төзекләндерү хезмәте күкертле нефтьне кудыру һәм аннан нефть продуктлары (ЭЛОУ-АВТ-7) эшләү һәм нефть продуктларын су ярдәмендә селектив чистарту (нафт) җайланмасы электр җиһазларына техник хезмәт күрсәтү һәм аларны төзекләндерү участогының электр җиһазларын төзекләндерү һәм аларга хезмәт күрсәтү буенча электромонтеры **Куляев** Мулланур Нургали улына, «КАМАЗ» гавами акционер җәмгыятенең тимерчелек заводы энергоремонт цехының электр җиһазларын төзекләндерү буенча электромонтеры **Петров** Юрий Павловичка, «Казан милли тикшеренү технология университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесенең «Союзхимпромпроект» проект институтының электротехника бүлеге төркеме җитәкчесе **Фатыйхова** Гүзәл Юныс кызына, «Татнефть-Энергосбыт» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте Елхово электр энергетикасы цехының электр җиһазларына сервис хезмәте күрсәтү участогы мастеры **Франко** Юрий Георгиевичка **«Татарстан Республикасының атказанган энергетигы»** дигән мактаулы исем бирелде.

ШИФАЛЫ ТӨЙМӘ – ТӘРТИБЕН КӨЙЛӘ

Даруларның файдасы 80 процент очракта аны ни рәвешле эчүеңә бәйле, ди белгечләр. Дару дигәнең кайчак агуга ук әйләнеп куярга мөмкин. Төймә йоттың да бетте түгел, кыскасы. Дару эчкәндә нинди кагыйдәләрне истә тотарга кирәк?



Табиб-терапевт Гөлия ГЫЙМАДИЕВА белән шул хакта сөйләштек.

:: Даруны бөтен килеш йотарга кыен булса, аны вакларга ярыймы?
– Юк, ярамый. Дарулар төрле булган кебек, аларны эчү тәртибе дә аерыла. Тышчалы, капсула рәвешендәге дарулар була. Аларны вакларга ярамый. Болай эшләгәндә, ашказаны аны авырдан сеңдерәчәк. Шуңа күрә төймә рәвешендәге даруны йота алмасагыз, аның сыек яки порошок рәвешендәге төрләрен эчегез.

:: Гадәттә, дару төймәсе уртасында аны ике өлешкә бүлә торган сызык була. Әгәр ул юк икән, даруның дозасын ничек чамаларга мөмкин?
– Икегә бүлә торган сызык булмаган дарударда компонентлар тигез урнашмый – аның теләсә кайсы почмагына чәчелгән була. Шуңа күрә аны үзлегеңнән ике өлешкә бүлгән очракта да дозасын дөрес чамалап бетереп булмый. Анннары кайбер дарулар махсус саклагыч тышча белән капланган була. Аны бозган очракта, дару составында матдәләр канга артык тиз эләгәчәк, шул рәвешле препаратның файдасы да булмаячак.

:: Даруны күпме су белән эчүең мөһимме?
– Дару эчкәндә стаканда ким дигәндә 50 мл су булырга тиеш. Кайбер дарударның кабында аларны күпме күләмдәге су белән эчәргә кирәклеге төгәл язылган була. Әйтик, ялкынсынуга каршы даруларның файдасы булсын өчен көненә 2 литр чиста су да эчәргә кирәк. Сидек куа торган даруларны эчкәндә исә су күләме бик аз булырга тиеш.

:: Кайчак даруны кул астында нинди су бар, шуның белән эчәргә туры килә бит...
– Бу – зур хата. Даруны чиста су белән эчүдән дә яхшысы юк. Сок, чәй, компот, газлы су – алар барысы да суда эретелгән билгеле бер матдә нигезендә ясалган. Алар аңа матур төс, тәм бирә. Шушы ук матдәләр дару составындагы матдәләр белән дә реакциягә керә ала. Моның инде нәтиҗәсе төрле булырга мөмкин. Алар йогынтысында дару организмга күчлерәк тәэсир итәргә яки, киресенчә, аның бер файдасы да калмаска мөмкин. Кайбер матдәләр зарарлыга ук әйләнергә мөмкин. Чәй, кәһвә белән йотып җибәргәндә, даруның бөтенләй бер файдасы да калмаска мөмкин.

:: Даруны су эчмичә, коры килеш кенә йотарга ярыймы?
– Дару йоткылык һәм ашказаны аша берниндн тоткарлыксыз, җиңел генә үтсен өчен аны су белән эчәргә кирәк. Моның өчен төкерек кенә җитми, шуңа күрә дару ашказанында озаграк тоткарланырга мөмкин. Шул рәвешле аның файдасыннан бигрәк зыяны күбрәк булачак. Ул күңелне болгатырга, ашказаны җәрәхәте китереп чыгарырга мөмкин. Шуңа күрә даруны һичшиксез чиста су белән эчәргә кирәк.

:: Даруны көнгә өч тапкыр эчәргә кушылган булса, аны ничә сәгать аерма белән кабул итәргә кирәк?
– Ул тулы бер тәүлек исәбеннән исәпләнә. Шул рәвешле көнгә өч тапкыр эчәргә кушылган икән, даруны һәр сигез сәгать саен кабул итәргә кирәк дигән сүз.

:: Вакытында эчәргә онытсаң, ни эшләргә?
– Даруны вакытында эчәргә кирәк. Юкса дәвалау курсының берннди файдасы да булмаячак. Даруны вакытында эчәргә онытакан очракта, табибыңа шалтыратып киңәшләшергә кирәк. Әгәр андый мөмкинлек юк икән, даруны тиешле вакыттан соң ике сәгать дәвамында эчәргә тырышырга кирәк. Ул чакта инде даруны икенче тапкыр эчәргә вакыт җиткән булса, беренчесен төшереп калдырырга кирәк. Гормональ даруларны, антибиотикларны ничек тә вакытында эчәргә тырышырга кирәк. Соңрак эчсәң, аларның бер файдасы да калмаска мөмкин. Көзән җыеруга каршы даруларны, антидепрессантларны вакытында эчәргә өлгермәсән, даруны икенче тапкыр эчәр чак җиткәнне көтү хәерлерәк. Бу дарулар бик көчле. Шуңа күрә кабул итү аралары якын булса, препаратның дозасы артып китеп, кеше агуланырга да мөмкин.

:: Билгеле булганча, исерек килеш дару эчәргә ярамый. Алкогольле эчемлек кулланганнан соң күпме вакыттан соң дару эчәргә мөмкин?
– Фәлән сәгать узгач кына дару эчәргә ярый дигән таләп юк. Дәваланганда алкогольле эчемлекләр кулланырга ярамый. Хәмер составындагы этанол даруның файдасын киметә. Ул гына да түгел, даруларның тискәре йогынтысы ук башлана. Кешенең косасы килә, башы авырта, йөрәк тибеше ешая, кан басымы күтәрелә. Кайбер кеше салкын тигәндә исерткеч эчемлекләр белән дәваланырга маташа. Шунда ук даруын да эчә. Әмма болай эшләү бик куркыныч. Хәтта кешенең бавыры, бөере таркалырга мөмкин.

НИНДИ ДАРУЛАРНЫ БЕРГӘ ЭЧӘРГӘ ЯРАМЫЙ?

Ике төрле даруны бергә кабул иткән очракта алар бер-берсенең көчен икеләтә арттыра яки, киресенчә, киметә ала. Шуңа күрә кайчак табиблар ике төрле даруны махсус берьюлы эчәргә куша. Шулай да бер-берсе белән һич кенә дә туры килмәгән дарулар да була. Мәсәлән:

➤аспирин + ялкынсынуга каршы дарулар = ашказанында язва китереп чыгарырга, эчәклекләргә зыян салырга мөмкин, хәтта кан китәргә дә мөмкин;
➤канны сыеклатучы антикогулянт дарулар + аспирин = инсульт, эчке кан савуга китерергә мөмкин;
➤эч киткәндә кулланыла торган дару + составында кальций булган дару = эчне катыруы бар;
➤активлашкан күмер + теләсә кайсы дару = дарулар организмнан юып чыгарылырга мөмкин;
➤ютәлгә каршы сироп + ютәлгә каршы порошок = составлары бер үк, шуңа күрә тиешле матдәләр күләме артып китеп, кеше агуланырга, даруларның тискәре йогынтысы көчәергә мөмкин.

Җимеш кенә димә...

Абау!

Киптерелгән җиләк-җимешне чамадан күп ашау симерү куркынычын арттыра. Медицина фәннәре докторы, Мәскәү дәүләт университетының фундаменталь медицина факультетының өлкән фәнни хезмәткәре Зөһрә Павлова шулай дип кисәтә. «Киптерелгән җиләк-җимеш, бер караганда бик файдалы, икенче яктан мәкерле дисәң дә була. Аларны еш кына сиропка манып киптерәләр», – ди Павлова.

Белгеч киптерелгән җиләк-җимешне дару кебек – аз-азлап һәм ашаганнан соң кабул итәргә киңәш итә. Эндокринолог киптерелгән җиләк-җимешнең файдасын да телгә алган. Мисал өчен, каражимеш эч катканда булыша, ә инҗир белән күрәгә йөрәк өчен файдалы.

Табигать даруханәсе

АНГИНА ВАКЫТЫНДА

✓**ЧӨГЕНДЕР СУЫ.** Моның өчен чөгендерне вак тишекле угычта уып, суын чыгаралар. 1 стакан чөгендер суына 1 аш кашыгы серкә (эссенциясен түгел!) өстиләр. Көненә 5–6 тапкыр тамакны чайкыйлар, бер йотым эчеп җибәрү дә зыянсыз.

✓**СУГАН КАБЫГЫ** саркындысы белән чайкау. 3 чәй кашыгы суган кабыгын 0,5 л суга салып кайнатырга, 4 сәгать тонәткәч, сөзәргә.

✓**САРЫМСАК ТӨНӘТМӘСЕ** белән чайкау. Чистарткан һәм вaклаган 100 г сарымсакка бүлмә температурасындагы 100 мл кайнаган су салып, өстен томалап 5–6 сәгать тотарга (24 сәгать тотарга да ярый). Шуннан соң сөзеп, җылымса көенчә тамакны чайкарга.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА әзерләде

ТИСКӘРЕ ЙОГЫНТЫСЫ БУЛЫРГА МӨМКИН. КУЛЛАНЫР АЛДЫННАН ТАБИБ БЕЛӘН КИҢӘШЕГЕЗ.

АЛМАНЫ КӨЗДӘН УТЫРТ

Илдар Мөхәммәтҗанов

Алма, груша үсентеләрен көзен утыртсаң, уңышны бер ел алданрак бирәчәк, ди Биектау районының Дөбьяз авылында яшәүче 74 яшьлек бакчачы Морис абый Нәгыймов. Дүрт ел элек Башкортстаннан күченеп килгән мичуринчы безнең шартларга туры килердәй сортларны үстерү, уйлап табу белән мәшгуль. Ул укучыларыбызга киңәшләрен дә бирде.

Заманасында агроном булып эшләгән, 40 елдан артык бакчачылык белән шөгыльләнгән Морис абый яшелчә, җиләк-җимеш үстерүнең бар серен белә. Бишбүләк районындагы Кыңгыр-Мәнәвез авылында туган Морис кечкенәдән бакча эшенә тартылып үсә. Әтисе Тәлгать – авылда беренче бакчачы. 27 төп алмагач утырта. 2 нче сыйныфта укучы Морис исә бу эштә – уң кулы. Малай шул елларда ук төрле җиләк-җимешләр үскән бакча булдыру турында хыяллана. Агрономия буенча техникум, вуз тәмамлый. Алты ел агроном булып эшләгәч, техникумда студентларга шул өлкәдә белем бирә.

Бакча булдыру хыялын 35 яшьтә генә тормышка ашыра егет. Бакчасында 29 сортлы алма, 19 төрле груша, виноград, абрикос, зелпе һәм башка җиләк-җимешләр үстерә. 1998 елда үсентеләр әзерләп сата башлый. Мул уңыш алу, саклау, чирләргә каршы көрәш чаралары турында махсус белешмә дә яза. Әлеге китапчыкны кабат яңартып чыгарырга нияте бар.

Питомнигында бүген 70 төп груша, 90 алмагач бар.

– Начар сортлар үстермим. Берсен дә аерасым килми. Арада җәйге, көзге һәм кыш буе ашый торганнары бар. Кемдер баллы «Конфетное» сортын, кемдер әчкелтемен сорый. Берәз әчкелтем һәм баллы сортларга «Анис алый», «Башкирский красавец», «Анис полосатый»ны кертәм, – ди Морис Нәгыймов.

Грушаның «Августовская роса» сортын иң тәмлесе дип саный. Быел беренче тапкыр хуш исле «Степенная» сортлы алмадан авыз иткән. Алмадан исә «Мечтательница», «Вишневый», «Юбилей Москвы»ны үстерә. «Дочь Папировки» август ахырында өлгерә һәм алмалар ике ай буе ботакта эленеп тора икән. Хәзерге вакытта Морис абый алмагачның – 14, грушаның 9 сортын үстереп сата.

– Соңгы 20 елда Россиядә безнең селекционерлар грушаның бик яхшы сортларын чыгара башлады. Башкортстан, Мичуринск, Свердловск, Мәскәү өлкәсендә уйлап табылган сортлар эре, тәмле булуы белән аерылып тора, – ди бакчачы груша турында. – Безнең шартларга «Лада», «Памяти Яковлева», «Заречная», «Октябрина», «Флейта», «Степенная» дигәннәре туры килә. Соңрак өлгерә торганнары – «Солтан», «Декабринка», «Гера». Соңгысы февраль азагына кадәр саклана. Аны алмагач кебек тәрбиялисе. Сортларны дөрес сайларга гына кирәк. Груша ботаклары өскә үрмәли, шуңа күрә очларын кисеп торырга онытмагыз. Җимеше озак сакланмый, суыткычка куярга кирәк. Алманы тартмада кыш буе саклар өчен араларына пычкы чүбе салыгыз.

Алмаларның зурлыгы – 80–120 грамм тирәсе. Татарстан селекционеры Осипов уйлап тапкан «Тиньковская» сорты – 200 грамм. 250шәр граммлы алма бирә торган «Жигулевская» сорты да бар әле. «Сенат Орловский» дигәне 300 граммга җитә. Бакчачы хәзер шул сортны өйрәнә. Грушаларның зурлыгы – 60–180 грамм чамасы. «Ульяновская» дигәне 250 граммга җитә. Эресен саклау авыр. Шуңа күрә 150 граммлысы да җиткән, дип киңәш итә бакчачы.

Сәрия МИФТАХОВА

ЧИРЛӘРГӘ КАРШЫ НИЧЕК КӨРӘШЕРГӘ?

Моның өчен ике препаратны кулланырга киңәш итә ул. 7 процентлы мочевина эремәсен көздән яфрак коелып беткәндә сипсәң, күп чирләр, күбәләк салган күкәйләр дә, гөмбә, кутырлар да юкка чыгачак. Көздән соңга калсаң, язын бөреләр уянганчы сибәсе. Микъдары: 10 литр суга 700 грамм мочевина исәбеннән.

Яз көне бөреләр күренә башлагач, 3 процентлы бакыр купоросын сибүнең дә файдасы зур. Җәен бу препаратның 1 процентлысын сайлап, 3–4 тапкыр сибәсе. Җимеш кортына каршы фуфанон яки аны алыштыра торган препарат кулланырга мөмкин. Моны алмалар баш бармак кадәр булганда башкарырга ярый. Бер корт сигез алмага зыян китерә. Барлык коелган алмаларны җирдән җыеп бетерергә кирәк.

Бакчачы әйтүенчә, сентябрь – алма, груша утырту өчен иң кулай вакыт. Үсудән туктаса да, тамырлар ноябрьгә кадәр ныгыячак. Яздан утыртсаң, үсентеләр 1–2 ай чирләп утырырга мөмкин. Гомумән, уңышның мул булуы үсентене дөрес итеп утыртудан тора. Сатып алуга ук утыртмасаң да була. Берәр көн балчык, су салынган суда тотарга мөмкин. Аннан чокырга тирес, бер үсентегә өчәр стакан азофоска яки нитрофоска ашламасы салып утыртасы. Суны 1–2 генә чиләк түгел, күбрәк итеп сибегез. Берәр атнадан су сибүне тагын шулай кабатлагыз.

«Солянка»

ГӨЛШАТ ИМАШЕВА РЕЦЕПТЫ

2 кг кәбестә, 2 кг помидор, 1 кг суганны турыйбыз, 1 кг кишерне кыргычтан уабыз. Шуңа 0,5 литр көнбагыш мае, 2 аш кашыгы серкә, 2 аш кашыгы тоз, 1 аш кашыгы шикәр комы, 15 данә кара борыч, 5 лавр яфрагы салып, бер сәгать пешерәбез.

Шулай ук солянкага гөмбә, яисә кыяр да өстәргә була. Гөмбәне салыр алдыннан 15 минут аерым пешереп, суын түгәргә кирәк.



Укучы киңәше

КИШЕР САКЛАУ СЕРЕ

✓Кишерне кышка саклау өчен аның сабагын җәлләмичә, яфрагы үреп чыкмаслык итеп фотодагыча кисәргә кирәк, ди Зөлфия Зиннәтуллина. Шулай кисеп, ком салмый гына чиләккә тутырып, капкач белән каплап базга куйсагыз, киләсе җәйгә кадәр менә дигән булып сакланачак. Болай эшләгәндә язын үреп, череп җәфаламый.

✓Без кисканнән соң кишерне юып киптерәбез. Аннары целлофан пакетларга биш-алты кило чамасы тутырып, зур капчыкларга салабыз да базга төшерәбез. Киләсе август аена кадәр җитә, әле калганын тавыкларга ашатабыз, ди Илсөяр Азизова.

ЯРАНГА ЙОД КИРӘК

Яран гөлләрегез ел әйләнәсе чәчәк атсын дисәгез, аны йод белән сыйлагыз. Юмартланып китеп артыгын сибеп җибәрә күрмәгез – аңа нибары бер тамчы да җитә. 1 л суга 1 тамчы йод болгатып, гөлнең төбенә түгел, ә туфракның чүлмәккә якын өлеше тирәли 50 мл чамасы сибеп чыгыгыз. Артыкка китсә, тамырларын яндыруы бар. Алда әйтелгәнчә сипсәгез, сезне яраннарыгыз купшы чәчәкләре белән сөендерер.

А. ГЫЙЛЬМАНОВА. Казан

Белеп тор!

Үрдәк чистарту буенча лайфхак

Бездә үрдәк өмәсе. Күп кеше, шырпылы, дип язгач, үрдәкләрем 90 көннән зуррак булсалар да, куркып торган идем. Интернетның файдасы тиде бит! Бер лайфхак табылды. Үрдәк пешекләп аласы кайнап торган суга бер уч чәй содасы салып, аны «сүндереп» алырга кирәк. Кайнар судан алгач, үрдәкне пакетка салып 3–5 минут тоткач кына йолкырга киңәш ителә. Болай эшләгәндә бер шырпысы да калмый, булса да, ул бик ансат чыга икән. Үрдәкләрне тиз эшкәрттек һәм алар чип-чиста булдылар.

Розалия ИБРАҺИМОВА

МАСАЮ ӨЧЕН ТҮГЕЛ

Яхшылык эшлә дә суга сал, ди халык. Адәм баласы гомер буе көченнән килгәнчә игелек эшләп, әҗер-савапка ирешергә тырыша. Яхшылыкны масаю, мактану өчен эшләүчеләр дә юк түгел. Моның өчен адәм баласын нәрсә көтә? Янына сәдака сорап килгән кешене борып җибәрергә ярыймы?

«Рөстәм» мәчете имам-хатыйбы Исмәгыйль хәзрәт БИККИНИН шул сорауларыбызга ачыклык кертте.

:: Динебез хәйрия, мохтаҗларга ярдәм итүгә нинди мөнәсәбәттә?

– Динебездә Аллаһы Тәгаләгә юнәлгән догаларыбыз, ураза, намазларыбыз гына түгел, җәмгыятькә, якын-тирәбезгә, туганнарыбызга мохтаҗларга күрсәткән фигыльләребез, гамәлләребез шулай ук эре савапка лаек булырга мөмкинлек бирә. Шуларның берсе – сәдака. Хәләл көч белән табылган малдан кешегә ярдәм итү ул. Кешегә ярдәм итү дә сәдака санала. Яхшы сүз, яхшы киңәш тә сәдака булып бара. Елмаюыбыз да – сәдака. Сәдака, иң беренче чиратта, Аллаһ ризалыгы өчен бирелә һәм бу сәдака иң элек кешенең үзенә файда китерә. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә: «Сәдака чыгару иманыгызның камиллегенә бер сәбәп булып тора», – ди.

:: Еш кына кеше берәр зур гөнаһ кылса яки моңа кадәр бик күп гөнаһлар кылган булса, берәр яхшылык эшләргә, мохтаҗга ярдәм итәргә, хәйриячелеккә кереп китәргә тырыша. Шул рәвешле гөнаһлары кичерелер дип өметләнә. Болай уйлау дөресме? Хәйрия эшләп, гөнаһлар кичерeләме?

– Гомәр ибн Хәттап үзенең хаталары турында искә төшергән вакытта: «Мин нинди дә булса хата, гөнаһ кылсам, күңелем тынычланганчыга хәтле кешеләргә ярдәм итәргә, сәдака бирергә тырышам», – дигән. Сәдака – хаталарыбызны юкка чыгаруга бер сәбәпләрдән санала. Ләкин кеше шул ук сәдака бирүне, мәчет төзү, күпер салу кебек саваплы эшләрне, кешеләргә белем бирүне гөнаһларны кичерү сәбәбе итеп күрми. Ул моны күбрәк Аллаһ ризалыгы өчен эшли. Әмма күпләр моны кеше гөнаһларыннан арыну өчен эшли дип кабул итә һәм ялгыша. Пәйгамбәребез үзенең бер сәхәбәсенә: «Хаталарыңны изге эш, сәдака, мәрхәмәтлелек белән капла, аларны күп итеп җибәр», – ди. Чынлап та, кайчак шундый хаталар була: син кирәкле кешеләрне табып гафу да үтенә алмыйсың. Шуңа күрә кешегә, җәмгыятькә ярдәм итсәк, файда китерсәк, без аны Аллаһ ризалыгы өчен сәдака булачак эшләсәк, ул безнең хаталарыбызның кичерелүенә бер сәбәп булачак.

:: Янына сәдака сорап килгән кешегә сәдака бирүдән баш тартсаң, бу гөнаһ саналамы?

– Юк, гөнаһ саналмый. Хәтта андый кешегә сәлам бирмәү дә рөхсәт ителә. Ник дигәндә, алар аны сиңа сәлам бирү өчен түгел, ә игътибарыңны җәлеп итеп, синнән сәдака сорар өчен эшли. Ислам динебездә хәтта мәчеттә, мәчет каршында хәер сорау тыела. Ник дигәндә, мөселман кешесенең үзенә карата абруе да булырга тиеш. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә кешеләрнең тыйнаклыгын, гадилеген мактый. Пәйгамбәребез бер хәдисендә: «Әгәр кеше бай булса, Аллаһы Тәгалә аның гадилеген ярата», – ди. Шул ук вакытта Аллаһы Тәгалә «Бәкарә» сүрәсендә: «Бар сезнең арагыздан шундый кешеләр, кайсылары Аллаһ юлына чыктылар һәм дә мал-мөлкәт кәсеп итәргә аларның мөмкинлекләре юк һәм алар үзләрен тыйнак, әдәпле тоталар, кеше өстеннән басып сәдака сорамыйлар», – дип ассызыклап әйтә. Урамнарда сәдака сорауны кәсеп иткән кешеләрне еш очратырга мөмкин. Аларга сәдака бирү тыела. Шул рәвешле син аларның ялкаулыгына, шушы гөнаһ гамәленә ярдәм иткән кебек буласың.

vk.com

Эчкечелек, наркомания кебек начар гадәтләре булган кешеләр бар. Аларга акчалата ярдәм бирү аларны шушы гөнаһка чумдыру булып тора. Шуңа күрә аларга ризык белән яки дәваланулары өчен акча түләп ярдәм итү хәерлерәк булачак.

:: Кайберәүләр, фәләнгә булыштым, ярдәм иттем, дип сөйләп йөри. Болай эшләү дөресме? Бу эшләгән изгелекләрнең әҗер-савабын киметмиме?

– Масаеп, мактанып йөрер өчен эшләнгән игелекләр, бирелгән сәдакалар Аллаһы Тәгалә каршында тузан бөртеге дә тормый. Шул уңайдан Аллаһы Тәгалә «Бәкара» сүрәсендә: «Кыя һәм ташлар өстендә яткан туфракны яңгырлар ничек юып төшерсә, сезнең мактануларыгыз һәм масаеп йөрүләрегез булган сәдакаларыгызны юкка чыгара. Үзегезнең сәдакаларыгызны мактану, масаю белән юкка чыгармагыз», – ди. Шуңа күрә без изгелекне иң беренче чиратта Аллаһы Тәгалә ризалыгы һәм үзебез өчен эшләргә тиеш. Асыл ниятебез дөрес булса, масаерга урын калмаячак. Әгәр кеше Аллаһы Тәгаләне беренче урынга куймаса, игелекле эшләре, кешеләргә күрсәткән ярдәмнәре масаю кебек килеп чыгарга мөмкин. Пәйгамбәребез андый кешеләр турында бер хәдисендә: «Сез үз косыгын ашаган эт шикелле булачаксыз», – ди.

:: Хайваннарга ярдәм итү адәм баласын җәннәтле дә итәргә мөмкин, диләр. Бу сүзләрдә хаклык бармы?

– Пәйгамбәребез бервакыт елаган бер дөяне күрә һәм аның хуҗасына: «Синең дөяң шикаять кыла: хуҗа ашатмый, өстемә гаять авыр йөкләр куя, ди», – дип әйтә. Шул рәвешле пәйгамбәребез аны малны вакытында ашатырга, өстенә авыр йөкләр салмаска кирәклеген кисәтә. Гомәр бин Габлегазиз вакытында халыктан сәдака һәм зәкят җыела, кешеләргә таратыла. Өйләнмәгән егетләр өйләнә, атланып йөрергә хайваны булмаганнарга мал сатып алалар, барча мал-мөлкәтне халыкка тараталар, кешеләргә йортлар төзиләр. Ләкин барыбер артык мал-мөлкәт кала. Шул вакыт Гомәр бин Габлегазиз тауларда булган кыяларга ярма таратырга, ашлыкларны чәчәргә әмер бирә. Хайваннар да, кошлар да аннан ризыклансын дип эшләнә бу. Ислам диненең гаделлеге дә менә шунда чагыла. Кеше кеше турында гына түгел, бу дөньяда бер халиф итеп билгеләнгән зат – хайваннар, җәнлекләр турында да борчылырга тиеш. Аларга ярдәм итү дә савап санала.

Бу – кызык!

НАМАЗ УКУНЫҢ НИНДИ ФАЗЫЙЛӘТЛӘРЕ БАР?

Татар сыйныфларына туплаганда, шәһәр балаларының туган телләреннән читләшә баруын күрәбез. Балаларны ясалма изоляциягә кертеп, саф татар телендә генә үстереп булмый. Аларның күбесе рус, татар телләрендә сөйләшә. Русча аңламаган балалар бик аз. Әле бит аның бөтенләй татарча белмәгәне дә күп. КФУ галимнәре ярдәмендә «Адымнар» мәктәбе өчен махсус дәреслек булдырдык. Башлангыч мәктәп өчен бар инде ул. Быел 5–6 нчы сыйныфлар өчен чыгар дип көтәбез. Әкренләп 11 нче сыйныфка кадәр җитәр, Аллаһ боерса. Бу – татар телен бик белмәгән балалар өчен әдәби телне өйрәтүче дәреслек. Иң мөһиме: ул төрле фәннәрдән терминологияне барлыкка китерә.

Татар теле өчен көрәш дәрестә генә түгел, мәктәпнең бөтен тәрбия эшендә алып барылырга тиеш. Һәр ата-аналар җыелышын үзем алып барам. Бондаренко урамындагы бинада аны бары татар телендә генә үткәрәм. Әти-әниләргә

Илдар Мөхәммәтҗанов

концерт, спектакльләр күрсәтәбез, үзебез нәфис фильмнар төшерәбез. Иганәче табып, аена 1–2 аудиоспектакль әзерлибез. Әти-әниләр балаларының кызыксынуын күреп рәхмәт әйтә.

:: Сездә әти-әниләр өчен дә татар теле курслары эшли. Килүчеләр күпме?

– Татар телен өйрәнергә теләгән утызлап әти-әни, укытучы атнага ике мәртәбә дәрескә йөри. Бу курслар татар теленә якынайтуны күздә тота. Аны тәҗрибәле татар теле укытучылары уздыра. Нәтиҗәсе бар.

:: Милли мәгарифтә нинди мәсьәләләрне хәл итәргә кирәк әле?

– Татар теле һәм әдәбияты укытучылары рус телле балалар белән дә эшли белергә тиеш. Күптелле укытучылар әзерләнә, әмма фәннәрне татар телендә укыта торганын табу авыр. Педагог табу гомумән җайлы эш түгел. Көллият, вузларны тәмамлаган барлык студентларны мәктәпкә җибәрсәк тә, укытучылар кытлыгы калачак. Бигрәк тә рус теле укытучыларын табуда кыенлык бар. Чөнки укучыларны БДИга әзерләргә кирәк. Атнага уртача 40ар сәгать дәрес биргән укытучылар бар. Бездә 300гә якын укытучы эшли. Татар мәктәбендә белем бирүче укытучыларның барысы да диярлек татарча белә.

:: «Адымнар»да беренче елларда татар мохите юк иде, әкренләп сизелә башлады, диючеләр дә очрый... Чыннан да бу шулаймы?

– Бондаренко урамындагы мәктәпкә кергәч үк сизелә ул. Мохит һәрвакыт бар. Кайбер балалар татарча белүенә карамастан, русча да сөйләшкәли. Андыйларга, татарча сөйләшегез, дип кисәтү ясыйм.

:: Бердәм программа, дәреслекләр булдыруга карата фикерегез ничек?

– Бер генә дәреслек калдыруга каршы мин. Дөньябыз, җәмгыятебез төрле кешеләрдән тора. Әмма алар бер-берсеннән аерыла. Барыбызны да бер төрле итеп киендерү дөрес түгел. Укытучының дәреслекне сайлап алу мөмкинлеге булырга тиеш дип саныйм.

:: «Адымнар» башка мәктәпләрдән кайсы ягы белән аерыла?

– Яңа федераль белем бирү стандартлары нигезендә миллилекне булдыру кыен. Шуңа күрә без дәрестән тыш эшчәнлеккә зур игътибар бирәбез. Моның өчен укытучыга акча түләнә. Өстәмә сәгатьләр кысасында 1–11 сыйныфлар өчен «Татарстан тарихы» укытабыз. «Татарстан Республикасы мәдәнияте һәм сәнгате» дигән курс та керә. Әгәр татар зыялыларын тәрбияләргә телибез икән, балалар милли музыка, композиторлар, гореф-гадәтләрне дә белергә тиеш.

Бездә төрле милләт балалары укый. Халыкара дуслыкны ныгыту, гореф-гадәтләрне саклауны күздә тотып, «Килешү фәлсәфәсе» дигән фән булдырылды. Баланы әкренләп мәктәпнең фәлсәфәсенә якынлаштыра торган курс бу.

Хәзерге вакытта, инглиз телен өйрәтүнигә кирәк, дигән фикерләр дә ишетергә туры килә. Чит телләрне өйрәнү бик кирәк. 1–11 сыйныфларда барлык укучылар да инглиз телен өйрәнә. 7 нче сыйныфтан исә математика, география, биологияне инглизчә укытабыз. Укучылар мәктәпне тәмамлаганда, инглиз телен белеп чыга. Без испан, гарәп һәм төрек телләрен дә өйрәтәбез.

Сәрия МИФТАХОВА

АКЫЛЛЫ КӨНДӘШ

ЯСАЛМА ИНТЕЛЛЕКТ ЕРАК КИЛӘЧӘК ТҮГЕЛ, Ә ЧЫНБАРЛЫК



tatarstan.ru

Җырга – көй, сөйләр өчен – шигырь, дәрес өчен инша да яза, табиб кебек, диагноз куя, рәссам сыман рәсем ясый, хуҗабикәләргә рецептлар тәкъдим итә, хәтта эшкә соңга калсаң, ни өчен соңга калуыңны аңлатырга җиңел булсын дип, сәбәбен дә уйлап таба! Ниндидер фантастик әсәр түгел, хәзерге чынбарлыгыбыз шундый.

Ни дәрәҗәдә рәхәт яшәвебез турында «нейрочелтәр», «ясалма интеллект» дигән төшенчәләр искә төшереп тора. Әле кайчандыр уенчык тоелган, бары тик программистлар һәм IT технологияләрнең нәрсә икәнен аңлаган кешеләр генә белгән бу күренешләр хәзер көндәлек тормышның бер өлешенә әверелеп бара. Алдарак әйтеп үткән эшләрне аларга кушу инде күптәннән мөмкин хәл. Күпләр шулай эшли дә. Әнә әле күптән түгел ясалма интеллект өлкән яшьтәге кешеләрне алдап көн күргән мошенникны тотарга ярдәм иткән дигән хәбәр дә чыкты. Бер акылда – күпме вазыйфа!

Тик бер рәхәтнең мең михнәте дә була шул ул. Киләчәктә бөтен эшне кеше уйлап тапкан ясалма аңга гына тапшырып, аннан гына эшләтә башласаң, кеше хезмәтеннән бөтенләй ваз кичмәбезме?

«Ясалма акыл безне ялкауландыра»

Киберкуркынычсызлык буенча аналитик Рәзилә Газизова, нейрочелтәрләрдән куркырга кирәк түгел, ди. Аларның да мөмкинлекләре чикле.

– Нейрочелтәрләр барлыкка килеп, гади кешене эшсез калдырачак дигән фәнни фантастика юнәлешендәге сүзләр – сафсата. Алай булмаячак, – ди ул. – Нейрочелтәр билгеле бер кагыйдә нигезендә генә эшли, ниндер уйлап чыгара һәм башкасы. Ә кешенең баш мие мөмкинлекләре чиксез. Ә нейрочелтәрләр баш миендә булган йөз кагыйдәнең берсе белән генә эш итә.

IT белгеч сүзләренчә, нейрочелтәрләр кешегә табигать аша бирелгән сыйфатларны, функцияләрне алмаштыра алмый. «Кешенең мөмкинлекләренә чикләр юк. Шуңа да ул яңа нәрсәләр уйлап таба», – ди Рәзилә.

Нейрочелтәрләрне куллану өлкәсе дә тар, ди Рәзилә. Мәсәлән, алар табиб урынына калып, катлаулы операция ясый алмас иде.

– Шик юк, ясалма интеллект көнкүрешебезгә бәйле мәсьәләләрдә булышчы. Тормышны җиңеләйтү ысулы. Вакыт барган саен, кешедә ялкаулык хисе арта. Әнә шуны аның куркыныч ягы дип күрәм. Бездә болай да инде «хезмәт күрсәтүгә корылган җәмгыять» өстенлек итә, – ди белгеч.

Үзгәреш җиле

«Касперский лабораториясе» эксперты Иван Квятковский әйтүенчә, нигезенә ясалма интеллект «салынган» уенчыклар тагын да артачак. «Бу өлкәне контрольгә алырлар, уйлап табуларны туктатырлар дип уйлау – ялгышу. Хәзер, киресенчә, ясалма интеллект өлкәсендәге тикшеренүләргә күп акча җәлеп итәләр», – дип саный белгеч.

Аның әйтүенчә, киләчәктә интернет эчтәлеген тәшкил иткән күпчелек материалларның (текст, сурәт, видео, уеннар) авторы ясалма акыл булачак. Иван фикеренчә, бу кешедән тагын да күбрәк игътибар, анализлау сәләтен арттыруны таләп итәчәк. Чөнки нәрсә укыганны, нәрсә караганны чамаларга, ак белән караны аерырга туры киләчәк.

– Ясалма интеллект күп кенә бурычларны үз өстенә алачак, шул рәвешле кешеләр башка мөмкинлекләрдән файдаланырга вакыт табачак, – дип тә өстәде ул.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

САН



Нейрочелтәрне үз эшегездә кулланасызмы? «Get experts» һәм «Comunica» агентлыклары Россиядә яшәүчеләрдән шул хакта сорашкан. Сораштыруда катнашучыларның 38 проценты «әйе» дигән.

Нейрочелтәр иң еш кулланыла торган өлкәләр

Финанс һәм хисап эшенә бәйле эшчеләр – **17** процент, белем бирү өлкәсе белгечләре – **17** процент, IT тармак вәкилләре – **13** процент, маркетинг өлкәсе белгечләре – **8** процент, юриспруденция – **8** процент, логистика – **3** процент.

НЕЙРОЧЕЛТӘР ФИКЕРЕ

Кәҗәсе түгел, мәзәге кызык, ди бит халык. Нейрочелтәр киләчәктә кайсы һөнәрләрне кысрыклап чыгарыр? Кемнәрне эшсез итәр? «ВТ» хәбәрчесе ясалма интеллектның үзеннән бу сорауларга җавап бирүен сорады. Алдан ук кисәтеп куюдөрес булыр: аралашу рус телендә барды, текстта нейрочелтәр тәкъдим иткән җавапларның туры тәрҗемәсе бирелдә. Фактик хаталар автордан түгел.

– Нейрочелтәр нинди һөнәрләргә тәэсир итәчәк?

– Нейрочелтәрләр бик күп профессияләргә йогынты ясарга мөмкин. Менә аларның кайберләре:

IT белгечләр. Нейрочелтәрләр программа тәэминатын уйлап табу ысулларын үзгәртергә, кул эше белән башкарыла торган бурычларны автоматлаштырырга мөмкин.

Медицина хезмәткәрләре. Нейрочелтәрләр диагностика һәм дәвалау эшендә булышчы була ала, шулай ук кеше факторының медицина практикасына йогынтысын да киметергә сәләтле.

Финанс аналитиклары. Нейрочелтәрләр финанс мәгълүматларын анализлауны яхшыртырга, инвестицияләр буенча карарлар кабул иткәндә булышырга һәм базардагы үзгәрешләрне фаразларга мөмкин.

Юрист. Нейрочелтәрләр юридик мәгълүматны эшкәртүне автоматлаштырырга, юридик эшләрнең нәтиҗәләрен фаразларга мөмкин.

Бу – нейрочелтәрләр тәэсир итә алган һөнәрләрнең кайбер мисаллары гына. Ясалма интеллект үсеше белән аларның йогынтысы башка тармакларда да үтеп керер дип көтелә.

– Ясалма интеллект кешене алмаштыра аламы?

– Ясалма интеллект элек кешеләр башкарган кайбер функцияләрне һәм бурычларны алмаштырырга мөмкин. Әмма мәгълүмати технологияләр өлкәсендәге үсешкә карамастан, кешедән фикерләү, иҗат итү һәм социаль күнекмәләр таләп итүче күп кенә бурычлар тулы автоматлаштыру өчен гаять катлаулы. Ясалма интеллект медицина, сәнәгать, финанс, белем бирү, транспорт кебек өлкәләрдә инде кулланыла, ул кайбер бурычларны кешегә караганда яхшырак һәм төгәлрәк үти. Әмма бу бит әле ясалма интеллект кешене тулысынча алмаштыра дигән сүз түгел. Иҗат, интуиция, социаль күнекмәләр һәм шәхесләр арасындагы аралашу кебек кешелек сыйфатлары әле дә кадерле һәм кирәкле. Кеше этик, әхлакый яктан карарлар кабул итә, вазгыятьне аңлый ала, әлегә болар ясалма интеллект мөмкинлекләреннән читтә тора.

– Ясалма интеллект журналистны алмаштыра аламы?

– Ул журналистның кайбер функцияләрен үти, әмма тулысынча алмаштыра алмый. Журналист мәгълүмат җыючы гына түгел, аны анализлаучы, интервью алучы, нәтиҗә ясаучы, кеше күзлегеннән чыгып язма әзерләүче…

– Миңа Татарстан турында текст кирәк.

– Татарстан – Көнчыгыш Европаның үзәк өлешендә урнашкан Россия Федерациясе составындагы федераль республика. Россия субъектлары: Башкортстан, Удмуртия, Чувашия, Мари Эл һәм Ульяновск өлкәсе белән чиктәш. Татарстан Республикасы 68 мең квадрат километрдан артык мәйданны били. Республиканың рәсми теле – татар һәм рус телләре. Татарстан халкының күпчелеге ислам динен тота, әмма монда шулай ук православие, католицизм, протестантизм һәм башка диннәр дә бар. Татарстан тарихи һәм мәдәни мираска бай. <…> Татарстанда татарлар, руслар, марилар, чуашлар, башкортлар һәм башка халыклар тату яшиләр, үзләренең милли традицияләрен һәм мәдәни мирасын саклыйлар һәм пропагандалыйлар. <…> Татарстан – мәдәни мирас, табигать һәм заманча инфраструктуралы республика. Монда тарих атмосферасына чумарга, табигый матурлыклардан ләззәтләнергә, милли ризыкларны татып карарга һәм кунакчыл халык белән танышырга мөмкин. Татарстан ял итү, сәяхәт итү һәм бизнес өчен кызыклы мөмкинлекләр тәкъдим итә.

– «Ватаным Татарстан» газетасы турында беләсеңме?

– Әйе, «Ватаным Татарстан» газетасы турында беләм. Бу – татарча төбәк атналык газета, ул сәясәт, икътисад, мәдәният һәм Татарстан җәмгыятенә багышланган темаларны яктырта. Газета рус һәм татар телләрендә нәшер ителә. Веб-сайты бар, анда да яңалыклар һәм мәкаләләр табарга мөмкин.

Гөлгенә
ШИҺАПОВА

КӨТӘ БЕЛҮЧЕЛӘР

БЕР ЕЛ ЭЛЕК ИЛДӘ ӨЛЕШЧӘ МОБИЛИЗАЦИЯ ИГЪЛАН ИТЕЛДЕ

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

«Энем киткән көн»

Апас районының Кече Болгаер авылы егете Илнур Закиров та махсус хәрби операциядә. Шушы бер ел эчендә ниләр үзгәргән? Шул хакта Илнурның апасы – язучы-журналист Гөлүсә Закирова белән сөйләштек.

– Энем махсус хәрби операциядә 7 ай хезмәт иткәннән соң ялга кайтып китте. Өлешчә мобилизациянең иң беренче көннәрендә повестка алган иде ул. Әле дә энемне озатырга дип кирәк-ярак җыйган чаклар искә төшә. Бик бәргәләндек ул вакытта, – ди Гөлүсә. – Энем ике ай инде алгы сызыкта. Әлбәттә, борчылып торабыз. Гаиләбезгә килгән бу хәсрәт әти белән әнине картайтты. Илнур ялдан китүгә, әнине хастаханәгә алып бардык, авыраеп китте. Инсульт кичергән әти картның да аяклары йөри алмас булды. Көчкә аякка бастырдык. Шөкер, уңайланып киләләр. Энем җае чыккан саен хәбәр бирә. Бакча, хуҗалык эшләре буенча бер ел инде безне контрольдә тота: аны казыгыз, монда утыртыгыз, шунда кадаклагыз. Сарыклар тота идек. Инде аларны бетерергә дип тә уйлыйбыз. Быел өй юганда тәрәзә янындагы обойга күз төште. Әни бәгырькәем «Илнур китте» дип язып куйган. Числолары белән. Үзе тәрәзәгә ятып елаган. Каршыдагы балалар бакчасы тәрбиячеләре күреп торган. Әниемнең йөрәгендә күпме сагыш яши. Әни сиздерми генә. Бик өзгәләнә инде.

Илнур Чечнядә хезмәт иткән була. Чакыру килгәч, бармый калу турында башына да китерми. Илне сакларга дигәч, сакларга! Җыена да чыгып китә. Авылдан берүзе бит ул.

– Энем киткәч, тормыш бөтенләй үзгәрде. Туганнар белән берләшүгә килгәндә... Без болай да дус, тату идек. Безгә уртак борчу артты. Иртәбез хәл белешүдән башлана. Барысы да бер сүз белән уяна: Илнурдан хәбәр бармы? Озак сөйләшми торсак, апам мәчеткә барып догалар укый, без гел бер теләктә торабыз – исән генә була күрсен, – ди Гөлүсә. – Хәзер бар да башкача. Күңел дә гел кителергә тора. Кемнәрдер синең борчуыңны үзенеке кебек кичерә, кайберәүләр аңламый да. Энем үзе, язмышыма шулай язылгандыр инде, ди. Чечнядән кайтканны, моннан да кайтачакмын, дип күңелне күтәрә.

«Тормышның кадерен белмәгәнбез икән»

Сабада яшәүче Гөлназ Хаева әнә шулай ди. Гаиләдә юк-бар өчен тарткалашу, үпкәләшү бер дә кирәкмәгән нәрсә булган икән, диләр ирләрен көтүчеләрнең барысы да. Гөлназ исә, Илнары кайткач, бер-беребезнең кадерен белер идек, ди.

– Иремне 29 сентябрьдә озаттым. Әле дә аның янымда юклыгыма ияләшә алмыйм. Бүген генә киткән шикелле. Ул чакта ничек алга таба яшәрмен дигән идем. Яшисең икән ул. Башта салкын кышны ничек ялгыз чыгармын, дидем. Яз да килде. Менә җәй дә узды. Инде янә көзгә кердек. Алда – кыш. Гомер сизелми дә уза. Аерылышып торуга да түзәсең икән. Яшәргә дә өйрәнәсең, – ди Гөлназ.

Гөлүсә Закированың шәхси архивыннан

Ире киткәч, Гөлназ үзен тиз кулга ала. Кеше янында эчендәге хәсрәтен сиздерми. Әмма кешегә күрсәтмичә генә балавыз сыгарга өлгерә. Әле бит өйдә улы бар.

– Кечкенә улым, әтисе шалтыратуга, минем янга килеп утыра. Ул да бик сагына. Әмма сиздерми. Бар нәрсәне эченә йота. Олы улым – Мәскәүдә. Ул әтисенең хәлен минем аша белешеп тора, – ди ул. – Без ирем белән эшне гел бергә эшләдек. Сменалы эштә булгач, буш вакытында күп эшне үзе башкара иде. Әле менә кураларны кисеп йөрдем. Узган ел бу эшләрне Илнар эшләгән иде бит. Ирем ялга кайткач, күп эшне башкарып китте. Тегермән тарттырып куйды. Тегендә дә безне кайгыртып ята. Гел борчылып тора.

Бер ел эчендә күпне аңладык. Ирем кайтса, юкка-барга борчылмыйча, тормышның кадерен белеп яшәр идек. Тизрәк илләр тынычлансын иде.

«Ирем белән горурланам!»

Саба районының Шәмәрдән бистәсендә гомер итүче Гүзәл Рамазанова әнә шулай ди. Иренең өйдән чыгып киткәненә 1 ел икән инде. Өлешчә мобилизация башлану хәбәрен кабул итү җиңел булмады, әмма шулай да үземне тыныч тоттым, ди ул.

– Ирем армиядән сержант дәрәҗәсендә кайткан иде. Илдәге хәлләрне чамалагач, мин үземне кулда тотарга өйрәндем. Ирләребезгә безнең елаганны күрү җиңел түгел икәнен беләм бит. Ничек итсәм иттем, көчле булырга тырыштым, – ди Гүзәл.

Тормыш өйрәтә аны. Ире янында булганда машина йөртергә өйрәнеп калуына да сөенә ул.

– Элек бик рәхәттә яшәгәнбез икән. Ирем китүгә тормышым үзгәрде. Әмма хатын-кызлар көчле бит алар, бөтен эшкә өйрәнәсең икән. Иң авыры – күңелдәге хисләр, – ди ул.

Бу көннәрдә ире янында, Данир ялга кайткан.

– Кызганыч, ялы бетәргә өч көн кала иремнең әтисе үлеп китте. Шул сәбәпле ялын озайттылар. Хәлебезгә керделәр, сентябрь азагында гына китәчәк, – ди Гүзәл. – Иремне кабат озату кыен булыр инде. Ничекләр аерылышырбыз... Ул китүгә, бер хәбәрен ишетү өчен янып яши башлыйсың. Исәнлеген белү дә җитә! Безнең ирләр сакламаса, илне кем саклар иде?! Ияләнәсең икән барысына да. Ул да аерылышып торуга ияләште, без дә сабырлыкка өйрәндек.

«Көнем иминлек сорап башлана»

Бу сүзне күпләр әйтә. Якыннары махсус хәрби операциядә булганнар гел догада тора. Әниләре дә өзгәләнә, әтиләре дә, туганнары да. Мамадыш районының Урта Кирмән авылында гомер итүче Ринат Хәйруллин да абыйсының улын көтә. Әтисе урынына калган абыйсының йөрәгендә тынычлык юк.

– Бертуган абыемның улы Рөстәм Хәйруллин бер ел инде махсус хәрби операциядә катнаша. Әтисе бик иртә, 29 яшендә арабыздан китеп барды. Ул чакта энемә 2 генә яшь иде әле. Шуннан соң киленебез үз ягына китеп барды. Башкортстанның Илеш районыннан иде алар. Энебезне ташламадык, кечкенә чагында гел барып, хәлен белеп тордык. Рөстәм буй җитеп, гаилә корды. Хатыны белән ике бала үстерәләр иде. Үзе дә ятим үскән энемнең балалары әтиле булсын иде, дип телим, – ди Ринат Хәйруллин. – Күптән түгел ялга кайтып китте. Янына барып, андагы хәлләрне сораштым. Уйландыра, күңелгә тия. Хәзер инде энем дә бөтенләй башка кешегә әйләнде. Тормышка карашы үзгәрде. Без дә үзгәрәбез инде. Һәр иртәм шул балага исәнлек, илгә-көнгә тынычлык теләп башлана хәзер.

Әти исе

Балтач районының Сасна авылында гомер итүче Рәзилә Бәдегыеваның өч туганы махсус хәрби операциягә чакырыла. Ике апасының уллары, ире Рамил Ватанны саклый.

– Өлешчә мобилизация буенча егетләрне чакыра башлагач, башта аңлап та бетермәдек. Энеләрем алданрак китте, ирем «Казан Экспо»да озак торды. Ике баламны кочаклап калдым мин. Ничекләр яшәрмен дигән көннәрем күп булды. Ирле тормыш ирле тормыш инде ул. Ирләрсез булмый икән. Хатын-кыз никадәр көчле булырга тырышса да, ир кирәк, – ди Рәзилә. – Әле ярый машина йөртә белә идем. Балаларны төрле түгәрәкләргә йөртәм. Авылда булсак та, машина бик кирәк. Быел кечкенә балам беренче сыйныфка керде. Кызым 5нчегә барды. Район җитәкчеләре икесен дә мәктәпкә әзерләргә булышты. Мунча ягар өчен утын да бирделәр. Ирләребез илне саклагач, безне кайгырталар инде. Гел хәлебезне сорашып торалар. Җәен йорт тирәсенә печән үсте. Районнан егетләр килеп, тәртипләп киттеләр. Шундый вакытларда ялгыз түгеллегеңне аңлыйсың, күңелгә рәхәт булып китә. Күп вакытта елыйсы килгәндә дә түзеп калырга өйрәндем. Бер безгә генә түгел, бөтен илгә килгән хәсрәт бит, дип тынычланам. Шулай итеп бер ел узып китте. Күңел бөтенләйгә кайтуларын көтә.

Рәзилә, балаларым белән юанам, ди. Кызы әтисен бигрәкләр ярата икән. Үскәч, әти кебек хәрби булам мин дә, дип хыялланa икән.

– Кызым барысын да аңлый. Әтисенең илебезне саклавын да белә. Аның белән горурлана. Әтисенә охшыйсы килә. Кечкенә улыбыз да әтисен бик сагына. «Әти кайчан кайта инде?!» – дип гел сорап тора. Аның киемнәрен иснәп йөри. «Әти исе килә», – ди. Ул да, үскәч, әтисе төсле булмакчы. Гаилә башлыгына хөрмәт зур бездә, – ди Рәзилә. – Мин үзем дә күп нәрсәгә өйрәндем. Ирем белән сөйләшкәндә: «Моңа кадәр бер дә яши белмәгәнбез инде», – дибез. Аерылышып тору барысына да өйрәтте. Парлы яшәүнең кадерен аңлатты ул. Рамил дә, өйдән китүгә дөньяга башкача карый башладым, күзләрем ачылды, ди. Күпме көтүләребезнең әҗерен күрербез әле. Бәхеттә яшисе көннәр алда булсын!

...Горурлану, сагыну, көтү, сабыр итү, үзгәрү. Кем белән сөйләшсәң дә, шул сүзләрне ишетәсең. Матур гына яшәгәндә ил өстенә килгән сынау күпләрне берләштерде, якынайтты һәм... ерагайтты да. Кыскасы, кемнең кем икәнен белергә өйрәтте. Якыннарын көтүче ханымнар сүзе бу. Аларда бер теләк: газиз кешеләре җиңү белән исән-имин өйләренә кайтсын иде! Фәрештәләрнең «амин» дигән чагына туры килсен бу сүзләр.



Рәзилә Бәдегыеваның шәхси архивыннан

РАБИТ БАТУЛЛА:

«УЛЛАРЫМНЫҢ УҢЫШЫНА СӨЕНӘМ, КАЙБЕР ОЧРАКТА КӨЕНӘМ»

Бу арада Батулла гаиләсенә игътибар зур. Кайчандыр улы Нурбәк күз уңында булса, хәзер Байбулат «Ядәч! Истә!» фильмы белән телдән төшми. Бу – без көткән фильм, дип сөенергә җирлек бар, әлбәттә. Гаилә башлыгы, фильмның төп геройларының берсе – Рабит БАТУЛЛА белән татар киносы, әдәбияты-сәнгате, тәнкыйть һәм көнчелек турында сөйләштек.

:: Рабит абый, могҗизага ышанасызмы?
– Могҗизага ышанмаган кеше әкият яза алмый. Минем иҗатымның күп өлеше әкияттән тора. Могҗиза ул... Коръән – могҗиза. Менә ул могҗиза! Һәм мин аңа ышанам.

:: Татар халкы өчен «Ядәч! Истә!» фильмы да – кечкенә генә могҗиза.
– Хыялланa белгән кешегә могҗизадыр.

:: Фильмда символлар шактый. Әйтик, бабай оныгына ядәч уенында оттырып, бер чиләк туңдырма ала һәм 1552 сум акча түли.
– Фильмның сценарий авторлары берничә. Мин моның кайсының фантазиясе икәнен әйтә алмыйм. Аны Казан ханлыгының егылуына бәйләп карыйлар. Бу дата символ булып аңга сеңгән инде. Шул ук вакытта аны күп кеше аңламый да.

:: Шулай булгач, милли кино ни хәлдә безнең?
– Бу сорауга Байбулат җавап бирде инде. Татар киносын булдырыр өчен тагын 400 ел вакыт кирәк, диде. Хәзер инде барысы да үзләреннән тора. Бәлки Байбулат та 30 елда берәр нәрсә эшли алыр. Әле бит ул гына түгел, режиссерлар байтак. Һәрберсе берәр генә яхшы фильм төшерсә дә, без дә, күкрәк кагып, милли кино дип сөйләшә алырбыз. Бу җиңел юл түгел. Такташ әйтмешли, бер мәрҗән табар өчен таулар ишәргә кирәк. Димәк, бер яхшы фильм чыксын өчен 100 фильм төшерергә кирәк. Анысы да ядәч уены кебек: я отасың, я оттырасың. Аннан соң бездә бит кино сәнгатебез дә, студиябез дә юк. Гәрчә төрки халыклар арасында 1926 елда ук иң беренче булып нәфис фильм төшерергә алынган халык булсак та. Безнең «Булат батыр» (1927), аннары «Койрыклы йолдыз» (1928) дигән фильмнарыбыз бар. Һәм алар – бүген дә карарлык әйбәт фильмнар.

> Башлангычы бездән чыкты, ә якутлар, казахлар эләктереп алды һәм алга чыкты. Алар инде бу өлкәдә тәҗрибәле, без әле юк. Киностудияң, павильонның булмагач, шулай инде ул. Алга таба әнә шул якны кайгыртырга кирәк. Менә әле бу фильмны хөкүмәттән бер тиен дә алмыйча эшләп чыктылар. Бу көннәрдә фильм прокатта. Чыгымнарын гына каплый алса да, бу инде бик зур уңыш була.

:: Бер әңгәмәдә: «Байбулат Казанга кайтачакмы?» – дип сорагач, сез, монда аңа күтәрелергә ирек бирмәсләр, дигән фикер әйткән идегез. Бу улегыздан кире кайтмадыгызмы?
– Мин хәзер дә шул фикердә. Казанда эшләмәсә дә, татарга хезмәт итә бит ул. Берничә фильм төшерде, кинофестивальләрдә уңыш казанды. Ләкин хөкүмәт ярдәме булмаса, аның иҗаты да төртелеп калырга мөмкин. Продюсер ярдәме ул бер, ике булырга мөмкин. Ә аннары?

:: Бездә синекенә-минекенә бүлү көчле. Роза Хәйруллинаны да «Зөләйха күзләрен ача» фильмыннан соң безнеке түгел дип әйтүчеләр булды. Бу хакта сез нинди фикердә?
– Роза – бик талантлы артистка. Аны үз фильмнарына алырга режиссерлар чират тора. Аны Байбулат катнашырга ничек күндергәндер – әйтә алмыйм. Күрәсең, ул да Казанга тартыладыр. Бик оста башкарып чыкты, ләкин... Розага безнең әбиләр риза булмаячак. Безнең татар карчыклары андый түгел, дип әйтәчәкләр. Минем геройның кыланмышларына да риза булмадылар. Мөселман кинофестивале шушы фильм белән ачылырга тиеш иде бит, мөфтият, аракы эчү күп дип, риза булмады. Һәм аны азакка куеп дөрес эшләделәр. Мин аның белән килешәм.

Ялганлап күрсәтеп булмый бит инде, халык эчә. Минем герой да эчә. Ул бала кайгысыннан эчә. Бәлкем андый күренешләрне киметергә дә кирәк булгандыр.

:: Өлкән яшьтә кино актеры буларак уйнау нинди тәэсир калдырды?
– Мин бик тыныч, аһ итмим. Вазгыятьне коткарырга кирәк иде бит. Байбулат кастинглар да үткәреп карады, бабайны уйнарга актер таба алмады. Шуннан алар минем көнгә калдылар. Эштә ата белән угыл мөнәсәбәте булмый. Монда режиссер белән актер мөнәсәбәте генә. Ул – баш, мин – буйсынучы. Әмерләрен үтәдем, ул риза калды кебек.

:: Татарга нинди фильм кирәк?
– Яхшы фильмнар кирәк. Тарих турында, яхшы әдәби әсәрләр нигезендә. Мин, мәсәлән, үзем бик күп сценарийлар яздым. Мәсәлән, «Алып батыр маҗаралары»н мин фильм итеп күрәм. Анда татар халкының тарихы, киләчәге. Анда бик күп фольклор материал файдаланылган. Аны төрекләр роман дип тәрҗемә дә итте. Байбулат әлегә минем иҗатка мөрәҗәгать итми, бәлки берзаманны тәҗрибә туплаган режиссер буларак кайтыр һәм минем иҗатка да мөрәҗәгать итәр. Тукай, Гаяз Исхакый, Кәрим Тинчурин, Сәйдәш, җыеп әйткәндә, мәшһүрләребез турында яхшы фильмнар булсын иде.

Кино сәнгатендә якутлар ни өчен алда? Кыргызлар, казахларда кино ничек шулай күтәрелеп китә алды? Ә бит хикмәте гади: алар фольклор белән алдыра. Мин аны малайларга да әйтәм. Заманча әйберләр белән кешене шаккатырып булмый хәзер. «Короче» фестиваленнән соң бу фикер тагын да ныгыды. Байбулат анда беренче урынны алды. Ә күпчелек картиналарда кәчләү, ирексезләү, кан, күз яше... Алар янында «Ядәч! Истә!» аерылып тора. Анда татар музыкасы, безнең фольклор. Әмма мин бу фильмга татар ябырылып йөрер дип уйламыйм. Беренчедән, халык кинотеатрга йөрүдән бизде. Ул инде телевизорга береккән. Икенчедән...

:: Шушы ук сорауны әдәбият өлкәсенә төбәп бирсәк, бүген нинди әсәр язылырга тиеш?
– Әдәбият кына түгел, мәдәният-сәнгать тә авыр хәлдә. Ниндидер торгынлык чорын үткәрәбез кебек. Нигә еллар, әдәбиятыбыз бай дип, эйфориядә яшәдек. Безнең әдәбиятыбыз череп бай. Черек мал белән ерак китеп булмый бит.

:: Димәк, яңа сулыш кирәк. Яңа дип әйтү – яшьләр иҗатын күз уңында тоту. Әмма яшьләргә нәкъ менә өлкән буын хәерхаһлы түгел.
– Яшьләр иҗатын карап, күзәтеп барырга тырышам. Ә инде аларны тәнкыйтьләү ул – табигый хәл. Пушкин заманында да шулай булган, хәзер дә. Картлар яшьләрне өйрәтергә тели, яшьләр дөньяны башкача күзаллый.

Мин гел хикәя эзлим. Миңа ошаган хикәя булса ярар иде, дип укый башлыйм. Ул бик сирәк була. Берәү, икәү... Яхшы әсәргә юлыксам, авторына ярдәм итәргә тырышам. Мәсәлән, Рәмзия Габделхаковaның «Даладан килүче» дигән хикәясе бик ошады. Шунда ук фикеремне яздым да «Казан утлары»на илттем. Ул басылып та чыкты. Шушы арада гына журналда чыккан проза әсәрләре турында яздым. Басарлармы анысын, юкмы – әйтә алмыйм, эндәшмәделәр әле. Тәнкыйть белән яздым чөнки. Тәнкыйть нигезле булса, файдалы. Инде сүгүгә корылган булса, зыянга эшли, кешене дә ялгыш юлга җибәрә.

«Татар-информ»

:: Уллaрыгыздан, шундый угыллар үстергән Рабит Батулладан көнләшәләрме?
– Көнчелекне тыеп булмый инде аны. Ул – дөньяның тискәре тоткасы. Ул һәр өлкәдә, һәр җирдә бар. Мин улларымнан канәгать түгел. Канәгать дигән сүз ул – «самодовольный дурак» дигән сүз. Аларның уңышына сөенәм, кайбер очракта көенәм. Алар күптәннән татар сәнгатенә хезмәт итәләр, шул яклары белән минем дәвамым дип саныйм. Нурбәк «Әлиф» спектакле белән «Алтын битлек» алып кайтты, Байбулат «Ядәч» белән беренче урынны алды, сөенеч түгелмени инде? Алга таба да җитди эшләр эшләргә икесенең дә мөмкинлекләре бар. Мин аларга, интервьюларда, бу әле минем иң әйбәт эшем түгел, дип әйтегез, дидем. Байбулатның да әле бу иң әйбәт фильмы түгел. Әле эшлисе дә эшлисе. Мактаулар бик күңелле, ләкин эйфориягә бирелергә кирәкми. Артык мактасалар да, хурласалар да, исегез китмәсен, дим. Талант ул ташны ярып чыккан үсенте кебек. Улларымның таланты да кыенлыкларны шулай бәреп чыгарга тиеш. Сартрның бер сүзе бар. Ул: «Котылыр өчен эшләргә кирәк», – ди. Улларым эшли, Аллага шөкер.

:: Иң зур теләгегез нинди?
– Милли азатлык.

Әңгәмәдәш – Гөлинә ГЫЙМАДОВА

НӘБИРӘ ГЫЙМАТДИНОВА

ШУНДЫЙ ИНДЕ БЕЗ...

(Бәян)

< Дәвамы. Башы 15 сентябрь санында

Сораудан битәр бу җан авазы иде. Онытылды Галиб, онытылды. Хис ташкыны ярыннан ташып акты... Әнә күңел төпкеленә чумган сер, йомычка төсле, дулкыннар кочагында чайкала. Хәер, ярдәмчесе берни дә сизмәде, егет, мактанырга дип, үз чиратын көтә иде.

– Аның каруы мин, синең әмерең белән, хәзерге татайларның көнкүрешен, гореф-гадәтләрен, холык-фигылен өйрәнгән идем, Остаз! Хәтерлисеңме?

– Һе, өйрәнгән ди берәү! – Галиб саран гына елмайды. – Ничәдер тәүлеккә җиргә индем дә зу-ур гыйльми хезмәт язарлык хәзинә тупладым, дисең инде. Юк, егетем, синең татайлар турында белемең бик сай әле.

Галиб уң кулыннан уй-ниятен яшермәскә тиеш иде. Моңарчы ярдәмчесе аның һәр йомышын карусыз үтәде. Бабай белән онык туганлык җепләрен өзелмәслек итеп үргән иде.

– Сиңа яңа планета ошыймы, Мирзам?

– Хи, ошамаган кая! Тикмәгә генә аны «җәннәт почмагы» дип атамадык бит, Остаз! Елга-күл сулары сабый баланың күз яшедәй саф-чиста, урман-кырлары ямь-яшел, кара туфрагы ашлы, бөртек тәртүгә бодае-арышы тишелә. Болынында аллы-гөлле йөзләгән төрдәге күбәләк канат җилпи. Ул исәпсез-хисапсыз чәчәк!

– Бөек Яралтучының кодрәте киң, барлыкка китерүче ул! Хәзер безгә бу гүзәл аймакны тутырырга кирәк, Мирзам. Мин аны җирдәгеләргә тәгаенләдем.

– Җирдәгеләргә?! – Ярдәмчесе колагын уды. Янәсе, ялгыш ишетә.

– Әйе, яңа урынга җирдән күчерәбез, Мирзам.

– Шура әгъзалары белән килештердеңме? Алар ни ди, Остаз?

– Сиңа мәгълүм, кайбер карарларны мин үзбаш кына хәл кылам!

– Әйе, син – безнең хөрмәтле хуҗабыз, исемең дә хаким дигәнне аңлата, Остаз.

– Аптыраш, планетада ике мең чамасы милләт яши. Җәннәткә кемнәр тиенер икән? Инглиз, француз, кытай, япон, негр...

– Санап интекмә, – диде Галиб. – Анда татай вәкилләре төпләнәчәк! Болай эшлибез, син теге чактагы кебек кабат Сыер исемле авылга сәяхәткә җыен, Мирзам. Сәнгать кешесе булып. Озакка. Араларында бутал, күзәт һәм иң акыллы, иң тырыш, иң булдыклы яшь парны барла. Шушы икәү яңа планетада хәр һәм бәйсез дәүләтнең нигезен корачак. Ары таба аларның сәясәтенә тыкшынмабыз, ярдәм генә күрсәтербез. Әүвәл яшьләр «җәннәт почмагы» белән танышсын, соңыннан халык санын ничек ишәйтәләр – алар ихтыярында. Йөзәрләгән кораб туктаусыз адәм ташыр.

– Әкә-ә-мә-әт... – Егет бу хәбәрдән тетрәнгән иде. – Сы-ер-га, Сы-ер-га, – диде ул, иҗекләп. – Хуп, Остаз! Таныш авыл. Бурычым да җип-җиңел. Ышанычың өчен рәхмәт!

– Киресенчә, бурычың авыр синең, сөенмә, Мирзам. Яшь пар тарафыннан минем дүрт шартым үтәлергә тиеш.

– Нинди шарт ул, Остаз?

– Беренчесе: яшь пар татай гаиләсендә милли рухта тәрбияләнсен, икенчесе: алар, без – татай, дип горурлансын, өченчесе: һәр туган сабыйның теле «әти, әни» дип ачылсын! Дүртенчесе: ил күләмендә татай теле дәүләт теле дип игълан ителсен!

–2–

«Бурычың авыр, сөенмә...» Мирзам пошаманга калды. Төптән уйласаң, шулай икән: авыр. Җирдә бер төн кунуың да ун елга тиң! Анда син бүген тере, иртәгә мәет! Адәмнәр бернидән дә тайчынмый, аса-кисә, сыта-изә. Сыер урамнарына бал сылаганнармыни, Остаз икенче тапкыр инде нәкъ шушы авылны сайлый. Югыйсә татай бөтен дөньяга сибелгән! Моннан егерме ел элек япь-яшь егет Сыерда тукталган иде шул. Халык авыз иҗаты өйрәнә, имеш. Чын дөресен әйт, беркем дә шиккә бата. Кунакчыл иде татайлар, һәр йортта йә каймаклы катык, йә итле бәлеш, йә пәрәмәч белән сыйладылар. Яратты ул ачык йөзле, киң күңелле әби-апалар белән мәзәк сөйләп көлдергән тешсез абзый-әзиләрне! Балактан йомшак кына тешләгән усал этләренә кадәр сөекемле иде. Айга борын чөеп өргәндә бу хайваннарның күзе яшьләнә, димәк, алар нәрсәдер сизенә иде... Эт җаны гына димә икән. Сыер хәтергә тирән уелган иде. Бер явыз метеорит, авылга якынлашканда, Мирзам аның юнәлешен үзгәртеп, казак даласында шартлаттырды. Татайлар өчен нинди генә игелекләр эшләмәс иде дә... Шура әһелләре Җир планетасын өнәми, әгәр Галиб остаз тыймаса, әллә кайчан нур белән өтеп куырырлар иде. «Шура» да хаклы анысы: әдәпсез бәндә бөтен тирә-юньне пычракка батырды.

Хуп, хуп, Мирзам «күрше»ләргә юл саба ди. Шунысы гаҗәп: Остаз меңләгән кавемне читкә тибәреп, татайга өстенлек бирә. Аның да Сыердагы яшьләренә! Әйтерсең үзе шунда туып-үскән! «Йә, телеңә салынма, кушканны үтә!» – дип егет корабның маршрутын билгеләде. Әзерлек тиз булды: киҗе-мамыктан тукылган киемсалым арка капчыгына салынды. Унлаган төймә белән бизәлгән беләзекнең вазыйфалары төрле-төрле, берсе – зәңгәр төстәгесе Остаз белән элемтә чарасы – аеруча кыйммәт иде. Тик менә йөз-кыяфәт мәсьәләсендә Мирзам икеләнде. Ике метрлы биокамерага кереп яткач, тән төзелеше табибы Мараж:

– Битеңне ник үзгәртсең? – диде.

Ха, Мирхам өймәс борын сиңа ком тавын ишә ди! Җир сәяхәте Остазның җиде йозакка бикләнгән сере иде.

– Кирәк! – диде ул, кыска гына.

– Кем буласың? Аксакалмы? Урта яшьләрдәге ир-атмы? Үсмер егетме?

Җир исәбе белән исәпләгәндә, Мирзамга утыз сигез яшьләр тирәсе иде.

– Хм... Кырык дисәк?

– Мәйлең, Мирзам!

Айлиягә дә шушы чама иде. Чү, нишләп бу оялчан кыз бала хәтер сүрүен ерта соң әле? Ике дистә ел элек ул егеткә мәхәббәт авыруы йоктырган иде. Әгәр дә мәгәр Мирзам тагын Сыер авылында атна-ун көн яшәсә, моның азагы фаҗига белән тәмамлана, ул җир кызын ярәшә иде! Шыр тиле! Сак хезмәте башлыгы аларны Центаврга якын да җибәрмәячәк, һавада ук очкычны аска мәтәлдерәчәк иде. Сизгер Остаз, бәлки корабка тидертмәс, ләкин Мирзам вөҗдан газабыннан яртылаш картаер иде. Ник дигәндә, Җиргә карата таләпләр каты, һәр сәфәрдән соң «тәлинкә» махсус сыекча белән чистартыла, ә сәяхәтче тәүлек буе күзәтү астында ята, чөнки иң куркыныч «дошман» Җирдә мыжлаган вирус иде. Йогышлы чир таралса, тиз генә тамыры корымый бит аның! Әлбәттә, галимнәр бер-бер әмәлен табар да иде, әмма моңа күпме вакыт сарыф итәрләр, күпме көч түгеләр, нәтиҗәдә үтә дә мөһим яңа ачышлар артка чигерелер, иң аянычы – бернинди даруларсыз үскән сау-сәламәт Центавр нәниләренең каны вакциналар белән агуланыр иде. Күрәсең, ул чакта яшь кенә булса да, Мирзам барысын да бизмәндә үлчәгәндер. Тикмәгә генә оялчан кыз белән аерылышмаган бит инде...

...Йөз-бит «ясалгач», егет экранга баккан иде, аңа зур авызлы адәм заты каш җыерды.

– Нишләп авызымны су буе ердың, Мараж?

– Ха, үзең кыяфәтем җирдәгеләргә тартым булсын дидең. Ә анда, әфәндем, бирәннәр төсле тыгыналар. Алар ашар өчен генә эшли, ашар өчен генә яши, шуңа күрә авызлары зурдин-зур!

Егет колагын капшады.

– Монысы да әкәмәтнең әкәмәте! Гайбәт тыңлый-тыңлый җирдәгеләрнең колагы әрекмән яфрагыдай киңәйгән дип шыттыр тагы! Уф, Мараж!

Ахырдан табиб белән килеште Мирзам. Үзгәрү аның файдасына иде. Сыерда халык ушлы, аны хәтерли булыр. Бигрәк тә Айлия! Туташ (бәлки бүген ир хатыны, бала анасы) егетне төсмерләп тә танырга тиеш түгел! Мөгаен, өздереп сайраган «май сандугачы»н ул кат-кат йөрәгеннән сызгандыр, ә менә егет озак «авырды», озак... Яулык чите белән иренен каплап, «яратам» дигән кыз төшләргә кереп җәфалый иде.

...Урман аланына «кунган» зәңгәрсу кораб яшен тизлеге белән киредән күккә атылып күздән югалгач кына, Мирзам аркасындагы биштәрен рәтли-рәтли, тар сукмактан атлады. Вак кына язгы яңгыр сибәли иде. Авылга табан илткән юл исә лыкыр балчык иде, егет аяк киемен салып һәм дә чалбар балагын сызганып май аеның соңгы пычрагы белән кәрәшкә ташлангында гына урман авызында, мичен якканмыни, төтенгә уралган йөк машинасы күренде.

Дәвамы бар >

Шигърият

Әнгам АТНАБАЕВ

НИ КАЛА КЕШЕЛӘРГӘ?

Бу арада йолдызлар да
Холыксызланды тәмам.
Йә анысы, йә монысы
Ычкына орбитадан.

Яшь йолдызлар – көзге әтәч,
Үзара очып куна...
Аларны, хәер, аңлап та,
Гафу да итеп була.

Инде килеп карт йолдызлар
Галәм алдына басып,
Тотындылар талашырга,
Күктән урын даулашып.

– Бер син генә йолдызмыни,
Мин йолдыз түгелмени?!
Әллә кемдәй кыланасың,
Бу личный күгеңмени?!

– Ә син күккә соңлап килдең,
Сөйләшер идең ипләп.
Ташбаш чүпләр башың белән
Йөремә йолдыз чүпләп!

Үзләре акыл бирердәй
Йолдызлар талашалар.
Тарихларда сирәк була
Мондыен тамашалар.

Әллә шайтан вәсвәсәсе
Йә иблис эше мәллә?!
Йолдызлар шулай кылангач,
Ни кала кешеләргә?!

ТАНЫП БУЕ

Танып буе карлыган,
Өзмим – сиңа калдырам.
Килгәнеңне көтә-көтә,
Күзләремне талдырам.

Танып буе әрәмә,
Керсәм, башым әйләнә.
Абау, бәгърем, чәчкәйләрем
Чәчләреңә бәйләнә.

Танып буе камышлы,
Камышлары сагышлы.
Ишеттеңме «яратам» дип
Пышылдаган тавышны?!

Танып буе болынлы,
Болынында булдыңмы?
Болыннарда адашырбыз, –
Бир, кадерлем, кулыңны!

Танып буе бөрлегән,
Өзеп сиңа бир, дигән.
Өзелеп сөйгән ярың өчен
Утка-суга кер, дигән.

Танып буе әрәмә,
Керсәм, башым әйләнә.
Абау, бәгърем, чәчкәйләрем
Чәчләреңә бәйләнә.

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

Татарстан Язучылар берлеге идарәсе, агасы **ХӘЛИМОВ Ингел Нәҗметдин улы** вафат булу сәбәпле, күренекле татар шагыйре Айдар Хәлимнең авыр кайгысын уртаклаша.

Дөге генә димәгез

– Сез салкын дөге боткасына кыяр кушып ашарга яратасызмы?
– Юк. Куз алдыма да китерә алмыйм.
– Ә чи балык белән?
– Юк, әлбәттә! Шундый ризык буламыни?
– Авокадо?
– Укшыта ук башлады.
– Ә майонез өстәсәк?
– Кирәкми!
– Бәлки, сезгә, алайса, суши яки роллы алып килергәдер?
– О! Ник аны алдан ук әйтмәдегез, бу бит минем иң яраткан ризыгым! Икесен дә алып килегез!



Әз-мәз мәзәк

– Мин Габдулла Тукай белән балалар бакчасында ук таныштым.

* * *

Нефтькә бәяләр төшүгә карамастан, бензинга бәя төшүне булдырмый кала алдылар.

* * *

– Ул җырчы мине үлемнән коткарды.
– Ничек итеп?
– Мин комада ята идем. Шәфкать туташы радио кабызып чыгып китте. Мин аны сүндерергә дип торып бастым.

* * *

Самолет исән-сау җиргә төшкәч, пилотларга кул чабабыз. Ә ни өчен такси белән кирәк җиргә барып җиткәч, кул чапмыйбыз? Таксида йөру дә кайвакыт бик куркыныч бит.

* * *

– Сезне яңа ысул белән дәвалаячакбыз.
– Ул ысулны куллангач, үлүчеләр юкмы әллә, доктор?
– Үлүчеләр бар, әмма дөрес симптомнар белән.



Сканворд җаваплары

Горизонталь: Апас, абзар, автор, ипле, Илсөя, Маруся, ил, этлек, ис, Кара, багучы, тынчу, Ту, менә, Ола, ур, Анфиса, казык, пәрдә, Аглая, факт, балл, Нократ, ОК, алкаш, аватар, як, Наиком, фен, пиар, төлке, тузбаш, урман, Ан, Лашман, Ибрай, Оби, Ксения, Вавилов.

Вертикаль: киту, бан, сырпалану, Әлки, акчарлак, раунд, Шота, Газинур, фән, Мөнир, Сати, оя, Киа, Азалия, усак, Карас, Павел, Аграфена, Ежи, арт, сиам, лаве, йон, өлгә, атан, Бидо, ария, ун, Талия, эчәк, Апуш, ты, афоризм, озак, аба, ешлык, яран, актык.

Беләсең килсә...

1 Казанда Сергей Королев кайда яшәгән?
а) Дәрвишләр бистәсендә;
б) Юдинода;
в) Социалистик шәһәрдә.

2 «Эскимос үбешү»ндә беренче чиратта кайсы әгъза катнаша?
а) ирен;
б) бит;
в) борын.

3 Русларда «дщерич» сүзе нәрсәне аңлата?
а) эшкә ярамаган такта;
б) апа ягыннан туган;
в) койрыгын югалткан кәлтә елан.

4 Бу торак пункт район үзәге сала:
а) Урыссу;
б) Ютазы;
в) Бәйрәкә.

Җаваплар: 1. в); 2. в); 3. б); 4. а).

Сәхифәне Данил СӘФӘРОВ әзерләде

Баш мөхәррирнең беренче урынбасары – ХӨСНУЛЛИН Илнар Хәлил улы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ, ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ АППАРАТЫ

Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2023 елның 23 августында теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – ПИ № ТУ16-01758.
Газета матбугат чараларының уэәк каталогына кертелгән.

Индекс П2435
Тираж – 14047 данә

Газетага сертификат бирелде
Заказ 331

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).

16+